Татарстан Республика Нурлат шәһәре 6 нчы номерлы "Кояшкай" балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

| Рассмотрено на педагогическом совете<br>От «22» 09 2020г<br>Протокол № 1 | Утверждаю<br>Заведующий МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» г. Нурлат Республики Татарстан»<br>_________________ Н.Н.Мугинова |
|---|---|
| | Введено в действие приказом заведующего МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» г. Нурлат Республики Татарстан»<br>От «23» 09 2020г. |

**Уртанчылар төркеменең ( 4-5 яшькә кадәр)**
**2020-2021 нчы уку елына**
**эш программасы**

Төзүче тәрбиячеләр: Мотыгуллина А.С.
Алексеева Э.М.
Әхмәдиева Н.И.

Нурлат, 2020

# Эчтәлек

**I.Максатчан бүлек.**
1.1. Аңлатмалы язу. ------------------------------------------------------------------------------------- 3
1.2.Программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру өченкирәкле характеристикалар. ---------------3-5
1.3. 4-5 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре ---------------------------------------------------5
1.4. Төркемнең социаль паспорты -----------------------------------------------------------------------5
1.5. Төркемнең өстенлекле юнәлеш эшчәнлеге.. ------------------------------ ----------------------6
**II..Эчтәлекле бүлек.**
2.1 Уртанчылар төркеме өчен оештырылган эшчәнлектә белем бирү өлкәләрен тасвирлау
1.“Физик үсеш” ---------------------------------------------------------------------------------------6-14
2. “Социаль-коммуникатив үсеш” -------------------------------------------------------------------14-17
3.“Танып-белү үсеше ---------------------------------------------------------------------------- 18-24
4.“Сөйләм үсеше” -------------------------------------------------------------------------------- 24-29
5. “Сәнгать– эстетик үсеш -----------------------------------------------------------------------30-50
2.2. Комплекслы - тематик план ------------------------------------------------------------------50-58
2.3.Уртанчылар төркемендә оештырылган эшчәнлектә вариатив формаларны куллану --58-61
2.4. Әти-әниләр белән эш. -------------------------------------------------------------------------62-66
**III.Оештыру бүлеге**
3.1. Материаль-техник база ----------------------------------------------------------------------66-70
3.2. Методик кулланмалар. -------------------------------------------------------------------------70
3.3. Атналык оештырылган белем бирү эшчәнлеге. --------------------------------------------70-71
3.4. Көндәлек режим --------------------------------------- -------------------------------------71-72
3.5. Үзенчәлекле вакыйгалар,бәйрәмнәр,мероприятияләә ------------------------------------ 72-73
3.6. Кулланылган әдәбият -- ----------------------------------------------------------------------73

# I.Максатчан бүлек

## 1.1 .Аңлатма язуы.

Бүген җәмгыятьтә катлаулы социаль-экономик процесслар бара, белем бирүнең кыйммәтләре һәм максаты тамырдан үзгәрә. Балаларга белем бирүнең бөтен өлкәләрендә дә актив, иҗади, үзенүзгәртергә әзер торучы шәхес тәрбияләү танылa. Балаларның шәхси һәм социаль мөнәсәбәт позициясен күздә тотып, аларны мәктәпкә әзерләүдән күчү, мәктәпкәчә белем бирү нәтиҗәләренең күзаллавын үзгәртергә булыша. Нәтиҗәлелек: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда кызыксынучанлык, активлык, мөстәкыйльлек сыйфатларын формалаштыра; ялгышларны уңышсызлыкларны җиңеп чыгаргаәзерлек, яңа белем алырга, стандарт булмаган ситуацияләрдән чыгу юлын эзләргә омтылыш тудыра; үзе сайлаган эшкә җаваплылык, командада эшли белү, үзенә, башкаларга, җәмгыятькә, әйләнә-тирәгә ихтирамлы караш, кайгыртучанлык тәрбияли. Болар барысы да баланы мәктәпкә әзерләп кенә калмый, ә хәзерге җәмгыятьтә уңышлы мөстәкыйль эшләү өчен нигез булып тора. Билгеле, мондый нәтиҗәләргә ирешү өлкәннәрнең фикер йөртүендәге үзгәртеп корулар белән бәйле, педагоглар һәм ата-аналар үзгәртеп коруда үзләре башлап йөрергә тиеш. Шунлыктан, Программа педагог-бала- ата-ана мөнәсәбәтенә ориетлаштырылган.

## 1.2.Программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле характеристикалар.

Бу программа "Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт таләпләре"нә нигезләнеп, Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге "Туганнан алып мәктәпкәчә"төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү программасына,балалар бакчасының еллык эш планына таянып төзелде.

Программаның төп бурычлары-мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру,шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләренә яраклаштырып, физик һәм психик сыйфатларны төрле яклап үстерү, баланы хәзерге җәмгыятьтә яшәргә, мәктәптә укырга әзерләү, мәктәпкәчә яшьтәге баланың куркынычсыз яшәү рәвешен булдыру. Бу максатлар бала эшчәнлегенең ( уен, аралашу, хезмәт, танып-белү, иҗади, уку) төрле процессларында тормышка ашырыла.
Программаны тормышка ашыру срогы - 1 ел (2019-2020 уку елы)
Эш программасы түбәндәге норматив документларга таянып төзелде:

*Белем бирү өлкәсендә федераль дәрәҗәдә:*

- 1.Федеральный закон от 29.12.2012 №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации».
- 2.Приказ МОиН РФ от 17.10.2013 №1155 «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования».
- «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы» 08.07.1992 № 1560 - XII
- "Порядком организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования» (приказ Министерства образования и науки РФ от 30 августа 2013 года №26, 2.4. 3049-13)
- Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 15.05.2013 г. №26 г. Москва «Об утверждении СанПиН 2.4.1.3049-13 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных образовательных организаций».
- Законом РТ «Об образовании» от 22 июля 2013 года № 68 – ЗРТ
- Примерной основной образовательной программой дошкольного образования- Научный руководитель проекта А.Г.Асмолов. Одобренной решением федерального учебного- методического объединение по общему образованию от 20 мая 2015 г. №2/15-М. издательство «Национальное обраование», 2015г.
- Общеобразовательной программой дошкольного образоания «От рождения до школы» Под.ред. Н.Е. Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой.- М:МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2014г

*Белем бирү өлкәсендә региональ дәрәҗәдә:*

- Балалар бакчасында Региональ белем бирү программмасы “Сөенеч- Радость Познание”/Р.К.Шәехова Казан: Мәгариф вакыт, 2016 ел.

*С документами локального уровня:җирле дәрәҗәдә:*

- Устав муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения города Набережные Челны «Детский сад № 6«Солнышко» утвержден постановлением Руководителя ИК от 29.03.2012 года № 1579.
- План работы МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» на 2019-2020 учебный год.
- «Основная общеобразовательная программа МБДОУ «Детский сад № 6 «Солнышко» на переходный период».

**Программаны тормышка ашыру максаты һәм бурычлары:**

**Программаның максаты:**баланың тулыкыйммәтле һәрьяклы үсешенә юнәлтелгән бер-бөтен укыту-тәрбия процессы төзүне тәэмин итү (физик, социаль-коммуникатив, танып белү, сөйләм үстерү, сәнгати-эстетик).

**Программаның бурычлары:**

1.Организмнарын даими рәвештә чыныктыру, оштырылга белем бирү эшчәнлегендә, шулай ук башка вакытта төп хәрәкәт төрләрен башкару осталыкларын һәм күнекмәләрен формалаштыру һәм камилләштерү, матур гәүдә, шулай ук гигиена күнекмәләре тәрбияләү өчен шартлар тудырып, балаларның сәламәтлекләрен ныгыту һәм саклануын дәвам иттерү;көндәлек режимны төгәл үтәү. Балаларның пространствода ориентлаша белүләрен камилләштерү. Күмәк уеннарда һәм физик күнекмәләрдә катнашуга дәртләндерү.

2.Мөстәкыйль хәрәкәт эшчәнлекләрендә уңай эмоцияләр, активлык формалаштыруга булышлык итү.

3.Әйләнә-тирәсендәге кешеләрнең тормышы һәм эшчәнлеге, табигать күренешләре белеп кызыксыну, тирә-юнендәге предметлар һәм күренешләргә игьтибар туплый белүне тәрбияләү.

4.Предметлар һәм күренешләр арасындагы бәйләнешләрне аңларга һәм шуның аша гади генә нәтиҗәләр чыгарырга белергә өйрәтү.

5.Өлкәннәр хезмәтенә уңай мөнәсәбәт формалаштыру.Көченнән килгән кадәр хезмәткә катнашу теләген уяту,кечерәк кыенлыкларны җиңә белергә өйрәтү.

6.Балаларның дөрес сөйләмнәренә: сүзлек составларын баетуга,җөмләләрне төзи белүләренә,сүзләрне дөрес һәм ачык итеп әйтүләренә ирешү.

7.Әдәби әсәрене азаккача тыңлый,әсәрләрдәдә вакыйгаларның ничек үрелеп баруын күзәтә белү сыфаты тәрбияләү.

8.Балаларның музыкаль сәләтләрен устерү, музыканың яңгырашындагы үзгәрешләрне тоя белергә өйрәтү.

9.Балалар бакчасында, өйдә, урамда,бердәм тәртип күнекмәләрен ныгыту.

Нәрсә яхшы һәм нәрсә начар булуы турында иң гади кузаллау формалаштыруны дәвам иттерү.

10.Балаларда әйләнә-тирәнең матурлыгына, сәнгать әсәрләренә эстетик караш тәрбияләү.

11.Кыска шигырьләрнең,шаян сүзләрнең мәгьнәсен аңлап сөйләргә, тормыштагы катлаулы булмаган предмет һәм ваыйгаларны рәсемдә,әвәләп сүрәтләр ясауда чыгылдыра белергә өйрәтү,җырның һәм музыкага туры килгән ритмик хәрәкәтләрнең тәэсирен аңлар дәрәҗәгә китереп җиткерү.

Программаны тормышка ашыруның төп принцибы- яшь үзенчәлегенә туры килү. Мәктәпкәчә чорда ул уен, тәҗрибәләр ясау, проектлау, коллекция туплау, әңгәмә кору, проблемалы ситуацияләрне чишү һ.б.Әлеге эш төрләре мәҗбүри эшчәнлекне таләп итми, ә бәлки Программа балалар һәм педагогларның бердәм эшчәнлеге, шулайук балаларның мөстәкыйль эшчәнлекләре аша тормышка ашырыла.

<u>Интегральләштерү принцибы</u>-предметлы белем бирү программасын төзүгә альтернатив. Һәр белем бирү өлкәсендәге бурычлар башка өлкәләрне тормышка ашырганда да үтәлә ала.Тәкъдим ителгән белем бирү өлкәләре шартлы, ул материалны системалы оештыру өчен бирелгән.

<u>Проблемалы белем бирү принцибы</u> – билгеле бер авырлыкларны җиңү өчен бурычларны үтәү, сорауларга җавап эзләү. Бала өчен проблеманың практик мәгънәсе

булу бик мөһим. Проблеманы чишеп, бала дөньяның күптөрле, үзгәрүчән булуын белә.

Ситуатив принцибы – белем бирү процессында балаларның кызыксынучан-лыгын исәпкә алуга юнәлгән.

### 1.3. 4-5 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре

Уртанчы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның уен эшчәнлегендә рольле мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу яшьтәге балалар кабул ителгән рольдән үзләрен аера башлыйлар.Уен процессында рольләр үзгәрергә мөмкин. Алар үзләре өчен түгел,ә уенны мәгънәле итү өчен уйный башлыйлар.Сурәтләү эшчәнлеге шактый үсеш ала. Рәсем предметлы һәм детальләштерелгән форма ала. Кешенең график сурәте гәүдә, күз, авыз, борын, чәч, кайвакыт кием һәм аның детальләре булу белән характерлана. Конструкцияләү катлаулана. 5-6 детальдән торган корылмалар барлыкка килә. Уйлап чыгарып конструкцияләү, шулай ук төзү эзлеклелеген планлаштыру күнекмәләре формалаша.Баланың хәрәкәтләнү өлкәсе вак,эре моториканың уңай үзгәрешләре белән характерлана. Җитезлек, хәрәкәт координациясе үсә. Кечкенәләр белән чагыштырганда балалар бу яшьтә тигезлекне яхшы саклыйлар, зур булмаган тоткарлыкларны атлап чыгалар. Туп белән күнегүләр катлаулана.Зиһенгә алу сәләте күбрәк үсеш ала. Балалар теге яки бу предметка охшаган форманы атый беләләр. Балалар предмет төркемнәрен сенсорик билгеләре- зурлыгы буенча тәртипкә салырга, биеклек, озынлык һәм киңлек кебек параметрларны аерырга сәләтле.Хәтер күләме үсә. Балалар 7-8 предметның исемен истә калдыра алалар. Алар олылар тапшырган эшне истә калдыралар, кечкенә шигырьләрне ятлый алалар.Тасвирлы фикерләү сәләте үсә башлый. Алар схема буенча төзи, лабиринтлы мәсьәләләрне чишә алалар. Алдан күрә белү сәләте үсә.Күз алдына китерү, уйлап чыгару сәләте үсә. Балалар мөстәкыйль рәвештә бирелгән темага зур булмаган әкият уйлап чыгара алалар. Игътибарлылык сәләте үсә. Бала 15-20 минут дәвамында игътибарын туплап эшли ала. Ул эш эшләгәндә катлаулы булмаган шартны хәтерендә тотарга сәләтле. Авазлар әйтелеше, дикция яхшыра. Сөйләм балаларның активлыкларын үстерә. Бала белән олыларның аралашу эчтәлеге үзгәрә. Бала өлкәннәрнең үзен ихътирам итүләрен тели, мактау сүзе аның өчен бик зур әһәмияткә була бара. Бу баланың артык үпкәләүчән булуына китерә. Шелтә, кисәтүләргә тискәре мөнәсәбәт туа. Артык үпкәләүчәнлек бу яшьнең феномены булып тора.Яшьтәшләре белән бала сайлап кына аралаша башлый. Ул кайбер иптәшләренә өстенлек бирә башлый. Уен вакытында даими партнерлар барлыкка килә. Төркемдә лидерлар аерылып чыга. Көндәшлек, ярышу барлыкка килә. Бу яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсү, рольле һәм тормышчан үзара бәйләнешләр барлыкка килү, сурәтләү эшчәнлеге үсү, үзең уйлап конструкцияләү, планлаштыру, зиһенгә алу сәләте камильләшү, образлы, хыялый фикерләү, танып-белүдә мин-минлек; хәтер, игътибар, сөйләм, дәлилли белү сәләте үсү, олыларның хөрмәтенә ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, ярышу кебек сыйфатлар барлыкка килү, Мин образының үсүе белән характерлана.

### 1.4. Төркемнең социаль паспорты

| | | |
|---|---|---|
| Төркемдә<br>27 бала | 14 кыз | 19 бала татар гаиләсеннән<br>2 бала рус гаиләсеннән<br>3 бала катнаш гаиләдән<br>3 бала чуваш гаиләсеннән |
| | 13 малай | |

### 1.5. Төркемнең өстенлекле юнәлеш эшчәнлеге

Программаны үзләштерү нәтиҗәләре булып мәктәпкәчә белем бирү ориентирлары тора:

• яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашулар (контакт урнаштыру һәм аны дәвам итү, уртак карарлар кабул итү, каршылыкларны хәл итү, лидерлык һ.б. ысуллары ничек үзгәрә);
• уен эшчәнлеге;
• танып белү эшчәнлеге (балаларның сәләтләре, танып белү активлыгы үсеше ничек бара); • проект эшчәнлеге (балаларның инициативалылыгы, җаваплылыгы һәм автономиясе үсеше ничек бара, үз эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру күнекмәсе ничек үсә);
• сәнгати эшчәнлек;
• физик эшчәнлек.

# II.Эчтәлекле бүлек.

## 2.1.Уртанчылар төркеме өчен оештырылган эшчәнлектә белем бирү өлкәләрен тасвирлау

### 1.“Физик үсеш”

Физик үсеш балалар сәламәтлеге өчен бик тә мөһим, чөнки ул аларның тумыштан хәрәкәткә омтылышын гамәлгә ашыру мөмкинлеге бирә. Балаларның бердәйлеге, «Мин» образы үсеше баланың физик үсеше, аның җитезлеге, хәрәкәтчәнлеге, активлыгы белән тыгыз бәйләнгән.

**Максаты:**

1.Балаларда физкультура шөгыльләнүгә кызыксыну һәм ныклы мөнәсәбәт формалаштыру.
2.Сәламәт яшәүрәвешенигезләренформалаштыру.
3.Гармонияле физик үсеш.

**Бурычлары:**

*1.Сәләмәтләндерүче:*

- Балаларның сәламәтлеген сакла, сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру.
- Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту.
- Ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру.
- Гигиена нормалары һәм кагыйдәләрен аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә үтәүләренә ирешү.

*2.Белем бирү:*

- Балаларның хәрәкәтләнү күнекмәләрен, аларны мөстәкыйль хәрәкәтләнү эшчәнлегендә иҗади куллана белүен үстерү һәм камилләштерү.
- Физик сыйфатларны үстерү.
- Балаларны үз сәламәтлеген ныгыту ысуллары турында гади белемнәрен үстерү.

*3..Тәрбияви:*

- Баалаларда физик күнегүләргә белән шөгыльләнүгә кызыксынучанлыкларын формалаштыру.
- Баланың күпкырлы гармонияле үсеше.

***<u>САФ ҺАВАДА ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР</u>***

Хәрәкәтле уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлекләрен ныгыта, хәрәкәт координациясен яхшырта. Әлеге уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш гамәлләр, хәрәкәтләрен барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен бапрышанда балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләренүзләштерәләр.

***<u>Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру.</u>*** Сизү органнарын (күзләр, авыз, борын, колаклар) аеру һәм атап әйтә белүне үстерү, аларның организмдагы роле һәм аларны ничек саклау һәм карау турында күзаллау булдыру. Иртәнге гимнастика , уеннар, физик күнегүләрнең яхшы кәеф тудырулары; йокы ярдәмендә көч яңару турында күзаллау формалаштыру. Балаларны организмның төрле органнарын һәм системаларын ныгытучы күнегүләр белән таныштыру. Чыныгуның кирәклеге турында күзаллау булдыру.Сәламәтлекнең кыйммәтле булуы турында күзаллау булдыру; сәламәт яшәү рәвеше алып бару теләге формалаштыру. Көндәлек тормышта гигиена һәм пөхтәлек күнекмәләрен саклау һәм үтәү ихтыяҗын формалаштыру.

**Һава ванналары.** Балаларга һава ванналары яхшы тәэсир итә. Һава ваннасы вакытында бүлмәдә температура 20-22 булырга тиеш, аннары бүлмәне алдан җилләтү юлы белән температураны акрынлап 17-18 ка, ә 2 яшьтән олы балалар өчен 15-16 ка кадәр төшерелә.
**Төймәле юл.** Тәймәләр өстеннән яланаяк йөрү баланың аягына уңай тәэсир итә.Ул нерв нокталарына көчле тәэсир итә, яссы табанлыкны, аяктагы арыганлыкны киметә.
**Ноктaлы массаж** – шулай ук күптәннән билгеле. Массаж төрлечә тәэсир итү үзлегенә ия: ул тирене йомшарта, кан әйләнешен , буыннарның сыгылмалыгын яхшырта , мускулларны һәм сеңерләрне ныгыта. Су-Джок терапия.
**Иртәнге гимнастикаларда** табанны формалаштыру өчен махсус күнегүләр төймәле юл өстендә йокы алдыннан дәвам итә. Бу исә яссы табанлылыкка юл куймый , әгәр булса бу кимчелекләрне бетерүгә ярдәм итә.

Чыныктыру процедураларын башкарганда түбәндәге рациональ гигиена шартларын һәм таләпләрен төгәл үтәргә кирәк:
- һаваның саф булуы ;
-бинадагы һава температурасының тиешле дәрәҗәдә булуы ;
-киемнәрнең температурага карап дөрес сайлануы ;
-хәрәкәт режимының активлыгы.

Шушы юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата – аналарга да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру принципларын өй шартларында

СЕНТЯБРЬ

| Оештырылган белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Темалар: Занятиянын этаплары:** | 1-нче атна “Белем көне.” | 2-нче атна “Белем көне.” | 3-нче атна “Көз.” | 4-нче атна “Көз.” |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр аша интегратив сыйфатларны үстерү:** Бер рәткә тезелеп йөрергә, йөгерергә, төрле юнәлештә йөгерергә өйрәнү; биеклектә йөргәндә равновесияны саклап калырга, алга этелеп сикерергә, туп бәрергә өйрәнү. Предметлар янынннан йөрүне һәм йөгерүне кабатлау; аяк очында йөрергә, предметка сикереп тияргә һәм тупны өскә бәрергә өйрәнү. Бер шеренгага тезелергә, йөрү һәм йөгерүне сигнал буенча чиратка салырга өйрәнү. | | | | |
| **ОРУ:** | Предметларсыз: Л.И.Пензулаева. | Туп белән: Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз: Л.И.Пензулаева. | Таякчыклар белән: Л.И. Пензулаева. |
| **Төп хәрәкәт төрләре:** | 1)Кулларны баш артына куеп гимнастик скәмҗя өстенә тезеп куелган туплар өстеннән атлап йөрү.<br>2)Алга тезеп куелган предметлар янынннан змейка ясап ике аякта сикереп йөрү.<br>3)Ике шеренгага бүленеп басабыз. Бер як шеренга балалары кулларына туп тотып икенче яктагыларга бер кулы белән тупны идәннән сикертеп бәрә, каршы як ике куллап тота. | 1) Ике аякта биеклеккә сикерү.<br>2)Кечкенә тупны өскә таба бәрү. (диаметры 6-8 см)<br>3)Салмак кына бер рәткә тезелеп йөгерү 1,5 минут.<br>4)Биеклеккә сикереп предметка тию.<br>5) Тупны өскә ыргытып, кулны чәбәкләп, ике куллап тоту.<br>6)Предметлар янынннан үрмәләп йөрү | 1) Гимнастик скәмья өстеннән үрмәләп йөрү.<br>2)Шнурны идәнгә җәеп шуның өстеннән кулларны билгә куеп янга таба.йөрү.<br>3)Ике кулга тупны тотып өскә бәрәбез, кулларны чәбәк итеп тупны тотабыз.<br>4)Ике шеренгага капма-каршы тезелеп басабыз, бер-беренә команда буенча баш өстеннән туп ыргытабыз(ара 2,5м)<br>5)Гимнастик скәмья өстеннән үрмәләп йөрү.<br>6) Баш өстенә | 1)Обруч эченнән янлап , обручка һәм идәнгә куллар белән тимичә, йөреп чыгу.<br>2) Алга бер рәткә тезеп куелган шакмаклар өстеннән башка мендәрчек куеп равновесияны саклап йөреп чыгу.<br>3)Бот арасына мендәрчек кыстырып ике аякта бер урында сикерү<br>4)Обруч эченнән турыга һәм янлап чүгәләп чыгу.<br>5) Алга бер рәткә тезеп куелган шакмаклар өстеннән башка мендәрчек куеп равновесияны саклап йөреп чыгу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | мендәрчек куеп кулларны билгә куеп шнур өстеннән янга таба йөреп чыгу | 6)Ике аякта алга таба этелеп сикерү. |
| **Хәрәкәтле уеннар:** | “Мышеловка” | “ Море волнуется раз..” | “Кармак” | “Ловишки”<br>“Тиз алып өлгер!” |
| **Аз хәрәкәтле уеннар:** | «Кемдә туп?” | “Тап һәм дәшмә!” | Сулыш күнегүсен ясап түгәрәк буенча бер колоннага тезелеп йөрү. | “Тап һәм дәшмә” |

ОКТЯБРЬ

<table>
<tr><td colspan="6">Оештырылган белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге:</td></tr>
<tr><td>Темалар:<br>Занятие этаплары:</td><td colspan="2">1-нче -2-нче атна<br>“Мониторинг.” “Мин дөньяның бер кешесе.»</td><td colspan="2">3-нче-4-нче атна<br>“Мин дөньяның бер кешесе.”<br>“Минем өем ,минем авылым.”</td><td>5-нче атна<br>“Минем өем,минемавылым.”</td></tr>
<tr><td colspan="6">Планлаштырылган нәтиҗәләр аша интегратив сыйфатларны үстерү: Балаларны 1 минут буена йөгерергә; скәмья өстеннән янлап йөрергә; сикерергә; тупны ыргыту буенча төрле күнегүләр өйрәтү.Түгәрәк буенча йөрегән вакытта , сигнал ишеткәч туктак кирегә таба барырга; Алга куелган каршылыклар өстеннән сикереп чыгып йөгерергә;биеклеккә сикерергә; тупны дорес итеп бәрергә өйрәнү. Йөрегәндә һәм йөгергәндә алга куелган каршылыклар өстеннән атлап йөрергә; 1 минут йөгерү; бадминтон уены белән танышу; сикерү уеннарын кабатлау.</td></tr>
<tr><td>ОРУ:</td><td>Предметларсыз:<br>Л.И.пензулаева.</td><td>Таякчыклар тотып:<br>Л.И.Пензулаева.</td><td>Туп белән:<br>Л.И.Пензулаева.</td><td>Обруч белән:<br>Л.И.Пензулаева.</td><td>Обруч белән:<br>Л.И.Пензулаева.</td></tr>
<tr><td>Төп хәрәкәт төрләре:</td><td>1)Кулларны билгә куеп гимнастик скәмья өстеннән янлап йөрибез.<br>2)Алга шнур сузып куела шуның аша уңга сулга таба ике аякта кулларны билгә куеп сикереп чыгарга.<br>3)Аякларны аерып басабыз тупны ике куллап күкрәк турысында тотып алга таба ыргытабыз.<br>4) балалар ике</td><td>1) Скәмья өстеннән ярым бөкләнгән ике аякка сикереп төшү.<br>2)(10-12 диаметрлы) тупны баш очыннан бер-береңә бәрү.<br>3)Гимнастик скәмья өстеннән үрмәләп йөрү.<br>4) Капма-каршы ике шеренгага тезелеп басып күкрәк турысыннан туп ыргыту</td><td>1) Алга куелган горизонталь максатка уң аннан сул кул белән туп бәрү. (2,5 м) .<br>2)Алга тезеп куелган дугалар астыннан идәнгә куллар белән кагылмыйча йөреп чыгу.<br>3)Алга куелган тутырылган туплар өстеннән кулларны билгә куеп атлап чыгу.<br>4)Гимнастик скәмья өстеннән янлап йөрү.</td><td>1)Алга бер рәткә тезеп куелган 3 обруч эченнән идәнгә куллар белән тимичә ян белән чүгәләп чыгу.<br>2)Гимнастик скәмья өстеннән уртасына куелган шакмак өстеннән атлап йөреп чыгу.<br>3)20 см биеклек мат өстенә ике аяклап сикереп менү.</td><td>1)Гимнастик скәмья уртасына куелган шакмак өстеннән атлап үрмәләп чыгу.<br>2)Кулларны билгә куеп гимнастик скәмья өстеннән йөрү, уртасына килеп җиткәч чүгәләп кулларны чәбәк итеп торырга һәм өйреп чыгарга.<br>3) 20 см биеклек мат өстенә ике аяклап сикереп менү</td></tr>
</table>

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | төркемгә бүленә(кызлар һәм малайлар) баштан кызларга туплар бирелә һәм аларга тупны бер кул белән алып бару техникасы күрсәтелә, аннан малайларга аңлатыла.<br>5)Капма-каршы басып бер-берсенә тупны бәрү. | | | | |
| **Хәрәкәтле уеннар:** | “Кошлар очып китәләр". | “Кармак” | “Җитез бул!” | “Гуси –лебеди” | “Мышеловка уены” |
| **Аз хәрәкәтле уеннар:** | “Тап һәм дәшмә” | Бер колоннага тезелеп йөрү. | Сулыш күнегүсен ясап түгәрәк буенча бер колоннага тезелеп йөрү. | “Оча-очмый” | “Затейники” |

НОЯБРЬ

| Оештырылган белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Темалар :**<br>**Занятие этаплары:** | 1-нче-2-нче атна<br>“Халык бөрдәмлеге көне.” | | 3-нче-4-нче атна<br>“Яңа ел килеп җитә.” | | 5-нче атна<br>“Яңа ел килеп җитә.” |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр аша интегратив сыйфатларны үстерү** : Тезләрне өскә күтәреп йөрүне кабатлау; шеренгаларга басып туп бәрүне өйрәнү .Йөгергәндә сигнал буенча юнәлешне кире якка үзгәртүне,предметлар янынннан йөгерүне;әле уң-әле сул аякта (чиратка салып сикерүне өйрәнү; гимнастик скәмя өстеннән үрмәләргә һәм тупны предметлар яныннан тәгәрәтергә өйрәнү. | | | | | |
| **ОРУ:** | Туп белән:<br>Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз:<br>Л.И.Пензулаева. | Туп белән:<br>Л.И.пензулаева. | Скәмьягә утырып:<br>Л.И.Пензулаева. | Скәмьягә утырып:<br>Л.И.Пензулаева. |
| **Төп хәрәкәт төрләре:** | 1)Кулларга тупны тотып үз тирәли тупны кулдан кулга күчереп скәмя өстендә йөрибез.<br>2)(2 метр) ераклыкка әле бер-әле икенче аякта(чиратка салып) сикереп бару.<br>3) (3 метр ) ераклыкта ике якка капма-каршы шеренгага тезелеп басабыз баш очыннан | 1) Әле уң-әле сул аякта алга таба барып сикерү.<br>2)Скәмягә корсак белән ятып куллар белән скәмя кырыйларыннан тартылып шуышып бару.<br>3)Тупны алга таба баш белән этеп(тәгәрәтеп) үрмәләп йөрү<br>4)Кулга тупны тотып идәннән сикертеп алга таба бару. | 1) Кулга тупны тотып идәннән сикертеп алга таба бару<br>2)Гимнастик скәмя өстеннән үрмәләп йөрү.<br>3)Обруч астыннан янлап һәм турыга таба йөреп чыгу.<br>4)Скәмя өстеннән кулларны билгә куеп ян белән йөреп чыгу.<br>3)Тутырылган туплар яныннан кулларны баш | 1) Шнур астыннан янлап һәм турыга таба чүгәләп чыгу.<br>2)Кулларны билгә куеп башка мендәрчек куеп гимнастик скәмя өстеннән йөреп чыгу.<br>3)Әле бер –әле икенче аякта(чиратка салып) сикерү.<br>4)Кулларны баш артына куеп предметлар яныннан аяк | 1) Шнур астыннан янлап һәм турыга таба чүгәләп чыгу.<br>2)Кулларны билгә куеп башка мендәрчек куеп гимнастик скәмя өстеннән йөреп чыгу.<br>3)Әле бер –әле икенче аякта(чиратка салып) сикерү.<br>4)Кулларны баш артына куеп предметлар яныннан аяк |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бер-береңә туп ыргытабыз | | артына куеп аяк очында йөреп чыгу | очында йөрү | очында йөрү. |
| **Хәрәкәтле уеннар:** | “Мышеловка” | “Ловишки” | “Кармак” | “Гуси –лебеди” | “Кошлар очып китәләр". |
| **Аз хәрәкәтле уеннар:** | “Тавыштан таны” | “Затейники” | Сулыш күнегүсен ясап түгәрәк буенча бер колоннага тезелеп йөрү. | “Оча-очмый” | «Кемдә туп?” |

ДЕКАБРЬ

| Оештырылган белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Темалар:** **Занятие этаплары:** | 1-нче атна 2- нче атна “Яңа ел” | | 3-нче 4-нче атна “Яңа ел.” | |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр аша интегратив сыйфатларны үстерү:** Йөрегәндә һәм йөгергәндә дистанцияне сакнарга;кыек такта өстендә йөрергә өйрәнү. Туп белән күнегүләр кабатлау. Кулларга тотынып түгәрәк буенча йөрергә һәм йөгерергә өйрәнү;әле уң -әле сул аякта сикерүне өйрәнү. | | | | |
| **ОРУ:** | Туп белән: Л.И.Пензулаева. | Флажоклар тотып: Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз: Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз: Л.И.Пензулаева. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Төп хәрәкәт төрләре:** | 1)Кыек такта өстендә кулларны билгә куеп ян белән йөрү.<br>2) Брусоклар аша ике аякта сикереп чыгу.<br>3)Ике шеренгага капма-каршы тезелеп басабыз,бер – береңә тупны баш очыннан ыргытабыз. | 1)Әле бер-әле икенче аякка таянып алга таба сикерү.<br>2) Өскә тупны бәрү һәм аны ике куллап тоту.<br>3) Предметлар янынннан үрмәп йөрү | 1)Капма-каршы ике шеренгага тезелеп басабыз(арасы 2,5м), зур диаметрлы тупны бер-беребезгә ыргытабыз.<br>2) Гимнастик скәмья өстеннән корсак белән шуышып бару.<br>3)Гимнастик скәмья өстеннән баш очына мендәрчек куеп йөреп чыгу. | 1) Гимнастик стена өстенә менү.<br>2)Скәмья өстенә шакмаклар тезеп куела, шул шакмаклар өстеннән атлый-атлый йөреп чыгарга.<br>3)Ике аякта предметлар янынннан икереп йөрү. |
| **Хәрәкәтле уеннар:** | “Ловишки” | “Идәндә утырып калма!” | “Аучы һәм куяннар” | “Хәйләкәр төлке” |
| **Аз хәрәкәтле уеннар:** | “Фигураны яса!” | “Кемдә туп?” | “Оча- өчмый” | Бер колоннага тезелеп йөрү. |

ГЫЙНВАР

| Оештырылган белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Темалар / Занятие Этаплары | 2-нче атна<br>“Кыш» | | 3-нче атна<br>“Кыш” | 4-нче 5 – нче атна<br>“Кыш” |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр аша интегратив сыйфатларны үстерү:** спорт залында кәшәкәләр һәм алка белән төрле хәрәкәтләргә өйрәтү; йөрү һәм алып баручыны алмаштырган һәм төрле юнәлешләрдә йөгерү вакытында киңлеккә йөз тота белү; эскәмияләр аша сикергәндә һәм борычтан сикергәндә куркынычсызлык техникасын саклый белү | | | | |
| **ОРУ** | Шайба белән<br>Л.И.Пензулаева. | Шайба белән<br>Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз<br>Л.И.Пензулаева. | Обруч белән<br>Л.И.Пензулаева. |
| **Төп хәрәкәт төрләре:** | 1) алканы бер кулдан икенчесенә күчерү<br>2) алканы аяк астында йөртү.<br>3) шайбаны өскә тәбә ырггыту<br>4) алка салу. | 1) алканы бер кулдан икенчесенә күчерү.<br>2) алканы аяк астында йөртү.<br>3) шайбаны өскә тәбә ыргыту<br>4) алка салу. | 1) бер-беренне әйләнә буенча чаналарда йөртү.<br>2) һаваны күзәтү.<br>3) таудан чанада шуу | 1.Гимнастик эскәмияләр буенча йөрү, уртада әйләнеш ясарга һәм алга таба узарга, рейс аша атлап сикерергә<br>2.Урыннан ераклыкка сикерү<br>3. тупны билгеләнгән урынга бәрү<br>4. Уң һәм сул як белән обручтан чыгу |
| **Хәрәкәтле уеннар:** | «Аю һәм бал кортлары” | «Аю һәм бал кортлары” | «Ябалак” | «Ябалак”<br>“Идәндә утырып калма!” |
| **Аз хәрәкәтле уеннар** | «Бөр коллонага төзеоеп йөрү” | «Бөр коллонага төзеоеп йөрү” | «Бөр коллонага төзеоеп йөрү” | “Оча – очмый уены” |

ФЕВРАЛЬ

| Оештырылган белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Темалар / Занятие этаплары | 1-нче атна<br>“Мактаулы солдат” | 2-нче атна<br>“Булачак Ватанны саклаучылар” | 3-нче 4-нче атна<br>“23 февраль бәйрәме” | |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр аша интегратив сыйфатларны үстерү:** балаларны йөгерүдә һәм сикерүдә күнегүләр башкарганда үз тәненең торышын күзәтеп торырга; балаларны спорт төрләре белән чаңгыда йөрү белән таныштырырга; дүрт аяклы йөрү элементлары белән уен хәрәкәтләрен башкарырга, тупны ыргытканда һәм тотканда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә; ике аяклы сикерүдә алга таба һәм киртәләр аша сикерүдә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә; | | | | |
| **ОРУ** | Предметларсыз<br>Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз<br>Л.И.Пензулаева. | Туп белән<br>Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз<br>Л.И.Пензулаева. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Төп хәрәкәт төрләре:** | 1сигнал буенча шеренгадан качарга, иркен йөгерергә һәм сигнал буенча шеренгага басарга.<br>2) сигнал буенча шеренгадан сикерергә, төрле юнәлешләрдә ике аяктан сикерергә һәм сигнал буенча шеренгага сикерергә.<br>3) сигнал буенча-ургычлар яткан мәйданның капма-каршы ягына йөгерү. | 1Скәмиядә йөгерү һәм сикереп төшү<br>2 эскәмия астына үтеп, аннан төшеп китү<br>3) скамейка аша үтеп кайту<br>4) оекбашларда йөгерү, утыру, әйләнеш. | 1) тупны өскә күтәрү һәм аска кадәр төшерү.<br>2) Туп тирәли йөгерү<br>3) тупны өскә бәреп зал бунча йөрү<br>4) туп тотып бер – берең артыннан йөгерү. | 1. куллар билдә, башка ком капчыгы куеп гимнастик скәмиядә йөрү.<br>2. бер – береңә туп бәреп, ике куллап тоту.<br>3. Скәмия аша сикерү.<br>4. Гимнастик стенкага үрмәләү. |
| **Хәрәкәтле уеннар** | «Аучы куеннар” | «Идәндә утырып калма” | “Капкан уены” | «Казлар уены” |
| **Аз хәрәкәтле уеннар** | Коллонада төзелеп йөрү | Коллонада төзелеп йөрү | Коллонада төзелеп йөрү | Коллонада төзелеп йөрү |

МАРТ

| Оештырылган белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Темалар Занятие Этаплары** | 1-нче атна “Халыкара хатын кызлар көне” | 2-нче атна “Халык мәдәнияте Һәм традицияләре” | 3-нче атна “Халык мәдәнияте Һәм традицияләре” | 4-нче атна “Халык мәдәнияте Һәм традицияләре” |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр аша интегратив сыйфатларны үстерү:** балаларны музыкадагы динамикалы үзгәрешләргә игътибар итәргә, зур киеренкелек белән хәрәкәтләргә күчү, ике аякта сикерү осталыгын һәм күнекмәләрен камилләштерергә; туп белән уен биремнәрендә куелган хәрәкәт бурычларын хәл иткәндә балалар интуициясен үстерергә; кыюлык, игътибарлылык тәрбияләргә өйрәтү. | | | | |
| **ОРУ** | Предметларсыз Л.И.Пензулаева. | Скакалка белән Л.И.Пензулаева. | Туплар белән Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз Л.И.Пензулаева. |
| **Төп хәрәкәт төрләре:** | 1) Музыка астында бармаклар өчен күнегүләр<br>2) шигырь тактына төрле хәрәкәтләр үтәү.<br>3) минем арттан хәрәкәтлә кабатлау. | 1) «Нурлар» күнегүе.<br>2)нурлар кебек музыкага хәрәкәтләнү<br>3) предметлар аша сикереп чыгу. | 1) Тупны сул һәм уң аяк белән тәгәрәтү.<br>2) тупны сул һәм уң кул белән әйләндерү.<br>3) тупны өскә бәрү<br>4) тупны гимнсатик скәмиядә тәгәрәтү. | 1)Тиз атлаганда приседание ясау<br>2) салапм аша чыгу<br>3) үрмәләү<br>4) Йомырка һәм кашык белән эстафета |
| **Хәрәкәтле** | “Казлар” | “Казлар” | «Аю һәм бал | «Карусель” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **уеннар** | | | кортлары” | |
| **Аз хәрәкәтле уеннар** | Коллонада төзелеп йөрү | Коллонада төзелеп йөрү | Коллонада төзелеп йөрү | Коллонада төзелеп йөрү |

АПРЕЛЬ

| Оештырылган белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Темалар** **Занятие этаплары** | 1-нче атна “Яз килде” | 2-нче атна “Яз килде –табигать уянды” | 3-нче атна “Галәм киңлекләре” | 4- нче атна “Тукай яши безнең күңелләрдә” |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр аша интегратив сыйфатларны үстерү:** ике аякта алга алга таба һәм каршылыклар аша сикерүдә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә, балаларны йөрештә, йөгерүдә, парка һәм колоннада үзгәртеп коруда күнегүләр ясарга; авыш яссы буенча йөрештәге тигезлекне саклый белүне камилләштерергә; югары таянычта йөрештәге тигезлек күнекмәләрен камилләштерергә өйрәтү. | | | | |
| **ОРУ** | Яулыклар белән Л.И.Пензулаева. | Чыбыклар белән Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз Л.И.Пензулаева. | Предметларсыз Л.И.Пензулаева. |
| **Төп хәрәкәт төрләре** | 1. Гимнастик скәмиядә йөргәндә борылып каршыякка китү.<br>2. Бер обручтан икенче обручка сикерү.<br>3. Билгеләнгән урынга уң һәм сул кул белән бәрү. | 1) смәмиядә тиз йөреп, карга сикереп төшү.<br>2) балалар карны куып тота һәм тота<br>3) кар бөртекләренә чыбык оргыту. | 1) Колонна буенча ике аякта сикереп бару<br>2) горизонталь максатка бәрү<br>3) баскычка менү һәм авыш юл буйлап төшү. | 1) алга таба ике аякта сикерү<br>2) ике аякта сикерү<br>3) Йөгерү белән сикерүне чиратлаштыру<br>4) Түбән бүрәнәгә сикереп менү<br>5)Бүрәнә өстендә йөрү. |
| **Хәрәкәтле уеннар** | «Аю һәм бал кортлары” | «Тукта» | «Кармак” | «Кармак » |
| **Аз хәрәкәтле уеннар** | Коллонада төзелеп йөрү | Коллонада төзелеп йөрү | Коллонада төзелеп йөрү | Коллонада төзелеп йөрү |

МАЙ

| Оештырылган белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Темалар** **Занятие этаплары** | 1-нче атна “Җиңү көне” | 2-нче атна “Җиңү көне” | 3-нче 4-нче атна “Яз” | |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр аша интегратив сыйфатларны үстерү:** балаларда традицион булмаган предметларны кулланып уен хәрәкәтләре шартларында тиз ориентлаша белү; бадминтон уйнаганда уен күнегүләренә өйрәтү; алга таба һәм киртәләр аша алга китеп, ике аякта сикерүдә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү; уен кагыйдәләрен үтәргә һәм уен барышында рольләр алыша белергә өйрәтү. | | | | |
| **ОРУ** | Чыбыклар белән | Флаглар белән | Флаглар белән | Обручлар белән |

| | Л.И.Пензулаева. | Л.И.Пензулаева. | Л.И.Пензулаева. | Л.И.Пензулаева. |
|---|---|---|---|---|
| **Төп хәрәкәт төрләре** | 1) чыбыкны төрле якка сөлтәү;<br>2) чыбыкларны ак түгәрәккә бәрү<br>3 ) чыбыклараша чыгу | 1) флаглар белән күнегүләр үтәү<br>2) флаглар утыру<br>3) флаглар тотып колоннада йөгерү<br>4) уң һәм сул якка дүрт аякта үрмәләү | 1) флаглар белән күнегүләр үтәү<br>2) флаглар белән утыру<br>3) флаглар тотып колоннада йөгерү<br>4) уң һәм сул якка дүрт аякта үрмәләү | 1.гимнастик скәмиядә тупны тотып йөрү.<br>2. Корсакта гимнастик скәмиядә шуышу<br>3. Сәмия аша сикереп чыгу<br>4.Гимнастик стенкага үрмәләү. |
| **Хәрәкәтле уеннар** | «Капкан» | «Капкан” | «Капкан» | “Капкан» |
| **Аз хәрәкәтле уеннар** | «Нәрсә үзгәрде уены» | «Нәрсә үзгәрде уены» | «Нәрсә үзгәрде уены» | «Нәрсә үзгәрде уены» |

**2.«Социаль –коммуникатив үсеш » белем бирү өлкәсе**

**Социальләштерү, аралашуны үстерү, әхлакый тәрбия .** Балалар бакчасында, өйдә, урамда үз-үзеңне тәртипле тоту күнекмәләрен ныгыту. Нәрсәнең яхшы һәм нәрсәнең начар булуы турында элементар карашлар формалаштыруны дәвам итү. Балаларны әхлакый тәрбияләү өчен шартлар тәэмин итү. Яшьтәшен кызгану, аны кочаклау, аңа ярдәм итү омтылышларын хуплау. Әйләнә-тирәдәгеләргә карата игътибарлы, кайгыртучан мөнәсәбәт формалаштыруга ярдәм итүче уен ситуацияләре булдыру. Балаларны тыныч, кычкырмыйча аралашырга өйрәтү. Бер-береңә карата дустанә мөнәсәбәт, иптәшең белән бүлешә белү, яхшы һәм начар гамәлләрне дөрес бәяләү тәҗрибәсе формалаштыру. Тату яшәргә, уенчыклардан һәм китаплардан бергә файдаланырга, бер-береңә ярдәм итәргә өйрәтү. Балаларны әдәплелеккә гадәтләндерү .

**Бала гаиләдә һәм берләшмәдә** «Мин» образы. Баланың үсүе һәм үсеше, аның үткәне, хәзергесе һәм киләчәге турында күзаллаулар («мин кечкенә идем, мин үсәм, мин зур булачакмын») формалаштыру. Балаларда аларның хокуклары (уйнарга, дустанә мөнәсәбәткә, яңа белемнәргә һ.б.) һәм балалар бакчасындагы төркемдәге, өйдәге, урамдагы бурычлары (мөстәкыйль ашау, киенү, уенчыкларны җыеп кую һ.б.) турындагы беренчел күзаллауларны формалаштыру. Һәр балада аның яхшы булуы, аны яратулары турында инанганлык формалаштыру. Беренче гендер күзаллауларын формалаштыру (малайлар көчле, кыю; кызлар мөлаем, нәфис). Гаилә. Балаларның гаилә, аның әгъзалары турындагы күзаллауларын тирәнәйтү. Туганлык мөнәсәбәтләре турында беренчел күзаллаулар булды- ру (улы, әнисе, әтисе, кызы һ.б.). Баланың өйдәге тормышта нинди бурычлары (уенчыкларны җыеп кую, табын әзерләүдә булышу һ.б.) булуы турында кызыксыну. Балалар бакчасы. Балаларны балалар бакчасы һәм аның хезмәткәрләре белән таныштыруны дәвам итү. Балалар бакчасы бүлмәләрендә ориент- лаша белү сәләтен камилләштерү. Балаларда әйберләргә карата сакчыл мөнәсәбәтне ныгыту, әйберләрне тиешенчә файдаланырга, аларны урынна- рына куярга өйрәтү. Балалар бакчасы традицияләре белән таныштыру. Баланың үзе турында коллектив әгъзасы сыйфатында күзаллауларын ныгыту, башка балалар белән бергәлек хисен үстерү. Балалар бакчасында төркемне һәм залны, участокны бизәүдәге үзгәрешләрне (затлы, матур уенчыкларның, балалар рәсемнәре- нең күркәмлеге һ.б.)күрә белү сәләтен формалаштыру. Фикер алышуга һәм мөмкин кадәр төркемне бизәүдә катнашуга, төркемнең символикасын һәм традицияләрен булдыруга җәлеп итү.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйльлек, хезмәт тәрбиясе**

Культура-гигиена күнекмәләре. Балаларда пөхтәлек, үзләренең тышкы кыяфәтләрен кайгырту гадәте тәрбияләүне дәвам итү. Мөстәкыйль рәвештә юыну, пычрануга карап, ашау алдыннан, бәдрәфтән чыккач кулларны сабынлап юу гадәте тәрбияләү. Тарак, кульяулыктан файдалану, йөткергәндә һәм төчкергәндә читкә борылу, авызны һәм борынны кульяулык белән каплау гадәтен ныгыту. Пөхтә ашау: ризыкны азлап алу, яхшылап чәйнәү, тавыш-тын чыгармыйча ашау, өстәл приборларыннан (кашык, чәнечке), салфеткадан дөрес файдалану, ашаганнан соң авызны чайкау күнекмәләрен камилләштерү.

Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Үзлектән киенү, чишенә белү күнекмәләрен камилләштерү. Өс киемен җыйнак итеп төрергә һәм эләргә, өлкән кеше ярдәмендә аны тәртипкә китерергә (чистарту, киптерү) өйрәтү. Җыйнак һәм пөхтә булу теләге тәрбияләү. Үз эш урынын мөстәкыйль рәвештә әзерләргә, рәсем, әвәләү, аппликация дәресләре төгәлләнгәч аны җыештырырга (кечкенә банкаларны, пумалаларны юу, өстәлне сөртү h.б.) өйрәтү.

Иҗтимагый-файдалы хезмәт. Балаларда хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт, хезмәт теләге тәрбияләү. Кушылган биремгә карата җаваплылык мөнәсәбәте (эшне ахыргача җиткерә белү һәм җиткерү теләге, аны яхшы башкару омтылышы) формалаштыру. Индивидуаль һәм коллектив йөкләмәләрне башкару, үз хезмәтенең башкалар өчен әһәмиятен аңлау тәрбияләү; тәрбияче ярдәмендә коллектив эшне бүлешү турында килешенү, уртак биремне вакытында башкарып чыгу турында кайгырту формалаштыру. Иптәшләренә, өлкән кешеләргә ярдәм итү инициативасын хуплау. Балаларны мөстәкыйль рәвештә балалар бакчасының төркем бүлмәсендә һәм участогында тәртип сакларга өйрәтү: төзелеш материалын, уенчыкларны урыннарына җыеп кую; тәрбиячегә китапларны, тартмаларны ябыштырырга булышу. Балаларны ашханәдә мөстәкыйль рәвештә дежурлык вазифаларын башкарырга өйрәтү: җыйнак итеп ипи савытларын, тәлинкәләре белән чынаякларны, тирән тәлинкәләрне урнаштыру, салфетка савытларын, өстәл приборларын (кашыклар, чәнечкеләр, пычаклар) кую.

Табигатьтәге хезмәт. Балаларның үсемлекләрне һәм хайваннарны карау- тәрбияләү теләген хуплау; үсемлекләргә су сибү, балыкларны ашату, суэчергечләрне юу, аларга су салу, улакка азык салу (тәрбияче катнашында). Балаларны язгы, җәйге һәм көзге чорларда булдыра алганча яшелчә бакчасында һәм чәчәклектә эшләүгә (орлыклар чәчү, су сибү, уңышны җыю), кышкы чорда кар көрәүгә җәлеп итү. Балаларны кошларга кышкы чорда ашату өчен үлән үстерүгә; кышлаучы кошларны ашатуга җәлеп итү. Тәрбиячегә хезмәт эшчәнлегендә кулланылучы җиһазларны тәртипкә китерүдә (чистарту, киптерү, тиешле урынга илтү) булышу омтылышын фор- малаштыру.

Өлкәннәр хезмәтенә ихтирам. Балаларны, игътибарларын якын кешеләре хезмәтенең әһәмиятенә юнәлтеп, аларның һөнәрләре белән таныштыру. Әти-әниләренең һөнәрләренә карата кызыксыну формалаштыру.

**Куркынычсызлык кагыйдәләрен формалаштыру**

Табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү. Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының күптөрлелеге, терек булмаган табигать күренешләре белән таныштыруны дәвам итү. Хайваннар һәм үсемлекләр белән үзара тәэсир итешү ысуллары, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында элементар күзаллаулар формалаштыру. «Ашарга яраклы», «ашарга яраксыз», «дару үләннәре» төшенчәләрен аңлауны формалаштыру. Куркыныч бөҗәкләр һәм агулы үсемлекләр белән таныштыру.

Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү. Күзәтүчәнлек, балалар бакчасында бина эчендә һәм участокта, якын-тирәдә ориентлаша белү сәләтен үстерү. «Урам», «юл», «урам чаты», «юл чаты», «җәмәгать транспорты тукталышы» төшенчәләре һәм урамда үз-үзеңне тотуның элементар кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү. Балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләрен

Сентябрь.

| № п/п | **Эшчәнлек төре** | **Атна** |
|---|---|---|
| 1. | Шәһәр урамнарында йөрүче транспорт төрләре.<br>Максат: балаларның шәһәр урамнары, андагы туктаусыз хәрәкәт турындагы белемнәрен киңәйтү. | 3 |
| 2. | Диңгез транспорты<br>Максат:балаларны диңгез транспарты тйрләре б/н таныштыру. | 4 |

Октябрь.

| № п/п | **Эшчәнлек төре** | **Атна** |
|---|---|---|
| 1. | " Төсле автомобильләр" уены.<br>Максат:уен аша балаларны юл кагыйдәләренә өйрәтү. | 1 |
| 2. | Җәяүлеләр өчен кызыл, сары, яшел төсләрнең әһәмияте.<br>Максат: юл билгеләре, светофор, аларның вазифалары турындагы белемнәрен ныгыту. | 2 |
| 3. | Светофор рәсемен һәм макетын карау.<br>Максат: балаларны светофор һәм аның кеше тормышындагы роле белән таныштыру. | 3 |
| 4. | А.Дороховның " Яшел, сары, кызыл" хикәясен уку.<br>Максат: балаларны матур әдәбият б/н таныштыру. Сорауларга җавап бирергә өйрәтү. | 4 |
| 5. | " Трамвай" уены.<br>Максат: уен кагыйдәсен төшенеп уйнау. | 5 |

Ноябрь

| № п/п | **Эшчәнлек төре** | **Атна** |
|---|---|---|
| 1. | Такси рәсемен карау.<br>Максат: башка транспорт чаралары төрләре б/н чагыштыру. | 1 |
| 2. | Шәһәр юллары турында призентация карау.<br>Максат: балаларны шәһәр юллары б/н таныштыру. | 2 |
| 3. | " Һәр машинаның үз урыны" уены.<br>Максат: уен аша транспорт төрләре б/н танышуны дәвам итү. | 3 |
| 4. | Бер яклы һәм ике яклы хәрәкәтле юл рәсем карау.<br>Максат:юл төрләре б/н танышу. | 4 |

Декабрь

| № п/п | **Эшчәнлек төре** | **Дата** |
|---|---|---|
| 1. | Поезд һәм тимер юл рәсемен карау.<br>Максат:балаларны тимер төшенчәсе һәм транспорт төрләре б/н таныштыру. | 1 |
| 2. | Тимер юл транспорты т-да шигырьләрдән өзекләр уку.<br>Максат:матур әдәбият аркылы тимер юл траспортларына кызыксыну уяту. | 2 |
| 3. | Тимер юл турында презентация карау.<br>Максат: тимер юлның үзенә генә хас үзенчәлекләре б/н танышуны дәвам итү. | 3 |
| 4. | Тимер юлда үзеңне тоту кагыйдәләре . | 4 |

| | | |
|---|---|---|
| | Максат: үз-үзеңне юлда дөрес тоту кагыйдәләрен искә төшерү. | |

Гыйнвар.

| № п/п | **Эшчәнлек төре** | **Атна** |
|---|---|---|
| 1. | " Кыен юл" уенын уйнау.<br>Максат: балаларның фикерләү сәләтен үстерү. | 2 |
| 2. | " Шофер" һәм " Машинист" рәсемнәрен карау.<br>Максат:рәсемгә карап кечкенә генә хикәя төзергә өйрәтү. | 3 |
| 3. | И.И.Кобитинаның " Нәниләргә техника турында" хикәясеннән өзекләр уку.<br>Максат:укылган хикәянең эчтәлеген аңларга ярдәм итү. | 4 |

Февраль

| № п/п | **Эшчәнлек төре** | **Атна** |
|---|---|---|
| 1. | Җигүле транспорт рәсем карау.<br>Максат: балаларны җигүле транспорт төре белән таныштыру. | 1 |
| 2. | " Атлар" уены.<br>Максат: рольләргә бүленеп уйнау. | 2 |
Музыка» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә Һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар музыкасына карата кызыксыну уяту, аны тыңларга теләк белдерү. Аның хисле-образлы эчтәлеге турында сөйләү, кичерешләр белән бүлешү.

Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлап, музыканың төп өч жанры: «җыр», «бию», «марш» төшенчәләрен бирү. Балаларның музыка характерын, кәефен бирә белү сәләтләрен үстерү.

Музыка уен кораллары (курай, кубыз, тальян гармун һ. б.) һәм аларның яңгырашы белән танышуны дәвам итү. Татар җырларын дөрес, сәнгатьле итеп һәм аңлап башкарырга, сүзләрен ачык итеп әйтергә күнектерү.

Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «чүгү», «аяк очларында күтәрелү», «берле бишек», «баш-үкчә», «култыклашып әйләнү», «борма» (гади вариант) һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү.

Музыка характерына туры китереп, ритмлы хәрәкәтләр башкаруны формалаштыру.

Хәрәкәтле импровизацияләрдә музыкаль образны чагылдырырга омтылуны хуплау, балалар белән бергә гәүдәләнеш вариантларын («тәкәббер» әтәч, «кайгыртучан» тавыклар, тик-тормас чебиләр һ. б.) тикшерү, музыкаль әкият эчтәлеге һәм характерына дөресрәк туры килә торган образны сайларга булышу, һәр иҗади табышны хуплау.

Балалар эшчәнлегенең төрле структурасына музыка өстәү; матур әдәбият, сынлы һәм театр сәнгатьләре әсәрләрен файдаланып, кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә ярдәм итәрлек музыка астында катнаш музыкаль эшчәнлек үткәрү.

| **Сентябрь. Тема:“Көз”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегральләштерү. | **1. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Музыканы тыңлаганда, эмоциональ халәт тудыру, характерын сиземләргә, фикерләрен әйтә белергә өйрәтү. | “Хәерле йокы”, А. Монасыйпов муз.; “Курчаклар маршы”, Н. Җиһанов муз., “Колыбельная”, А. Гречанинов муз. ; “Марш”, С. Прокофьев муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Музыкада аваз югарылыгын ишетү сәләтен үстерү. | “Кошлар һәм кошчыклар”. |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Балаларда җырлау күнекмәләрен формалаштыру. | “Гөмбәгә”, Н. Бакиева муз. “Кукушечка”, р.х.җ., И. Арсеев эшк. |
| | *б) Җырлар.* | Балаларны сәнгатьле итеп җырларга, дөрес сулыш алырга өйрәтү. | “Балалар бакчасында”, Н. Зарипова муз.; “Баю – бай”, М. Красин муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Музыкаль сорауга мөстәкыйль рәвештә җавап бирергә өйрәтү. | “Исемең ничек? – А –де – ля!” |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Музыканың характерына туры китереп, хәрәкәтләрне мөстәкыйль рәвештә үзгәртергә өйрәтү. | “Марш”, Л. Шиһабетдинова муз.; “Аллы – гөлле гөлчәчәк”, т.х.к., М. Мозаффаров эшк.; “Ах вы, сени мои, сени”, р.х.к., М. Раухвергер эшк. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *б)Сәхнәләште релгән этюдлар.* | Музыканың характерына туры китереп, “барабанчы” хәрәкәтен ясарга, җиңелчә аяк очларында йөгерү хәрәкәтләрен ясарга күнектерү. | “Барабанчы”, З. Хәбибуллин муз.; “Весёлая прогулка”, П. Чайковский муз. |
| | *в) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Уен күнегүләрен сәнгатьле итеп күрсәтә белергә өйрәтү. | “Яңгыр”, т.х.уен жыры Ф. Шәймәрданова эшк. |
| | *г) Музыкаль һәм җырлы уеннар* | Музыка характерына туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп башкарырга өйрәтү.<br>Җырның сүзләренә туры китереп, уенны сәнгатьле, күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | “Үз кәрзинеңне тап”, (“Вальс”), Х.Вәлиуллин муз.<br>“Көз”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Төрле образларны сәнгатьле итеп күрсәтә белергә өйрәтү. | “Аю бии”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *е) Балалар музыка уен коралларында уйнау.* | Гади генә көйләргә агач таякларда кушылып уйнарга өйрәтү. | “Тукран”. |
| | **II.Мөстәкый ль сәнгать эшчәнлеге** | Уен эшчәнлегендә ишетү сәләтен камилләштерү. | “Где мои детки?”, Н. Кононова муз. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Балаларның иҗади сәләтләрен үстерү. | “Хәйләгә каршы хәйлә”. Сәхнәләштерелгән чара. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **О к т я б р ь .  Т е м а : “ Мин кешелек дөньясында”** | | | |
| | **Музыка эшчәнлегене ң оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлар** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегралләштерү | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **2. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Балаларда музыка өлкәсендәге белемнәрен үстерү. Музыканың эчтәлеген аңларга. Тасвирлау чараларын ишетә белергә өйрәтү. | “Шома бас”, т.х.ж., Р. Еникеева эшк.; “Көз көне”, М. Мозаффаров муз.; .“Как у наших у ворот”, р.х.к., Т. Ломова эшк. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Ритмны тою сәләтен үстерү. | “Минем шикелле уйна”. |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Сүзләрне ачык итеп әйтеп, бер югарылыкта күңелле итеп башкарырга өйрәтү. Күнегүдә аваз югарылыгын формалаштыру. | “Карга”, Н. Бакиева эшк.; “Качели”, Е Тиличеева муз. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *б) Җырлар.* | Җырларны сәнгатьле итеп җырларга, дөрес итеп сулыш алырга, ягымлы итеп җырларга өйрәтү. | “Көз килде”, Л. Хисмәтуллина муз.; “Көзге моң”, М. Әндәрҗанова муз.; “Осень наступила”, Е. Насауленко муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Мөстәкыйль рәвештә бишек җырлары көйләрен иҗат итәргә өйрәтү. | “Әлли – бәлли”. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Музыканың характерына туры китереп, ритмлы итеп атларга, тыныч кына йөрергә,сикереп барырга өйрәтү. Музыканың башына һәм ахырына игътибар итү. | “”Марш”, Л. Хисмәтуллина муз.; “Якты таң”, Җ. Фәйзи муз.; “Марш”, Э. Парлов муз.; “Скачут лошадки”, Т. Попатенко муз. |
| | *б)Сәхнәләштерелгән этюдлар.* | Музыка характерына туры китереп, хәрәкәтләрне мөстәкыйль рәвештә ясарга өйрәтү. | “Коелган яфраклар вальсы”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *в) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Бию хәрәкәтләрен предметлар белән сәнгатьле, сыйфатлы итеп башкарырга өйрәтү. | “Яфраклар белән бию”, Ф. Шөймәрданова муз.; “По улице мостовой”, Т. Ломова эшк. |
| | *г) Музыкаль һәм җырлы уеннар.* | Уен күнегүен музыка характерына туры китереп башкарырга өйрәтү. | “Кайсыбыз юк?”, (“Пьеса”), Р. Еникеев муз.; “Куянкай, сорыкай”, т.х.уены. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Уен күнегүен күңелле, мавыктыргыч итеп, образны сәнгатьле итеп күрсәтә белергә өйрәтү. | “Аю бии”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *е) Балалар музыка уен коралларында уйнау.* | Балаларны агач таякларда музыка астында уйнарга өйрәтү. | “Тукран”, т.х.сүз. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Уен эшчәнлегендә ишетү сәләтен камилләштерү. | “Ну – ка, угадай – ка”, Е. Тиличеева муз. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Әкиятләргә кызыксыну тәрбияләү. Күңелле бәйрәмнән балаларда шатлык хисләре уяту. | “Ата каз”, Бияләй театры. (т.х.к.) “Сөмбелә”. Бәйрәм. |

| **Ноябрь. Тема:“Минем илем, минем шәһәрем”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социал- | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **3. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Музыканың эчтәлеген аңларга, тасвирлау чараларын ишетә белергә өйрәтү. Әсәрне бүленмичә һәм бүлдермичә ахырына кадәр тыңларга өйрәтү. | “Куянкай – сорыкай”, Л. Б. – Болгари муз.; “Новая кукла”, “Болезнь куклы”, П. Чайковский муз. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Тембрны аера белү һәм динамик төсмерләрне ишетү сәләтен үстерү. | “Нәрсәдә уйныйм?”(гармун, курай, металлофон, бубен, барабан). |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Көйне дөрес итеп көйләргә өйрәтү. Аваз югарылыгын формалаштыру. | “Бәлли – бәү”, т.х.к.; “Эхо”, Е. Тиличеева муз. |
| | *б) Җырлар.* | Җырны сәнгатьле итеп җырларга, дөрес итеп сулыш алырга өйрәтү. Музыка уен коралына кушылып һәм кушылмыйча җырларга өйрәтү. | “Тыныч йокы”, Ф. Шәймәрданова муз.; “Осень”, Ю. Чичков муз., “Песенка о маме”, С. Разорёнов муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Бирелгән текстка көйлә чыгару сәләтен үстерү. | “Елның дүрт фасылы – көз”, Г. Тукай сүз. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Уен күнегүләрендә музыканың характерын чагылдырып, җиңелчә йөгерергә, ритмлы итеп сикерергә өйрәтү. | “Сәрия”, т.х.к., Р. Еникеева эшк.; “Сикерү”, Р. Кәлимуллин муз.; “Вертушки”, укр.х.к., Я. Степовой эшк. |
| | *б)Сәхнәләштерелгән этюдлар.* | Музыка характерына туры китереп, мөстәкыйль рәвештә таралып һәм бер – бер артлы атларга, йөгерергә өйрәтү. | “Яшь солдатлар без”, М. Мозаффаров муз.; “Танец осенних листочков», А. Филиппенко муз. |
| | *в) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Түгәрәктә берәрләп һәм парлап йөрергә, әйләнергә өйрәтү. “Төп йөреш”, “Баш – үкчә”, “берле бишек хәрәкәтләрен сыйфатлы итеп башкарырга өйрәтү. | “Парлы бию”, Л. Шиһабетдинова муз.; ”Приглашение”, укр.х.к., Т. Ломова эшк. |
| | *г) Музыкаль һәм җырлы уеннар.* | Уен күнегүләрен сәнгатьле итеп күрсәтә, сәхнәләштерә белү сәләтен үстерү. Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | “Курочка и петушок”, Г. Фрид.; “Алтын капка”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Җырның сүзләренә туры китереп, бию хәрәкәтләрен күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | “Песи баласы”, М. Мозаффаров муз.; “Огородная – хороводная”, Б. Можжевелов муз. |
| | *е) Балалар музыка уен коралларында уйнау.* | Балаларны агач таякларда ритмлы итеп уйнарга өйрәтү. | “Тра – та – та”, т.х.с. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Мөстәкыйль рәвештә музыка уен коралларын кулланырга өйрәтү. | Таныш музыкаль – дидактик уеннар. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Әкиятләргә кызыксыну тәрбияләү. Күңелле бәйрәмнән балаларда шатлык хисләре уяту. | “Калач”. Сәхнәләштерелгән чара. “Әнием, кадерлем!” Мәктәпкә әзерлек төркеме |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | балалары концерты. |

**Д е к а б р ь .  Т е м а : “ Я ң а  е л  б ә й р ә м е ”**

| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
|---|---|---|---|
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **1. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Балаларның фикерләрен баету. Музыканың эчтәлеген аңларга, тасвирлау чараларын ишетә белергә өйрәтү. Әсәрне бүленмичә һәм бүлдермичә ахырына кадәр тыңларга өйрәтү. | “Балалар ярдәм итә”, З. Хәбибуллин муз.; “Күңелле бию”, А. Леман муз.; “Вальс”, Н. Җиһанов муз.; “Вальс снежных хлопьев”, П. Чайковский муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Жанрны аера белү һәм музыкаль хәтерләрен үстерү. | “Ак калач кемне очрата?” |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Көйне дөрес итеп көйләргә, сәнгатьле итеп сузып җырларга өйрәтү. | “Буранда”, Ф. Җәләлетдинова эшк.; “Цветики», В. Карасева муз. |
| | *б) Җырлар.* | Җырларны сәнгатьле итеп җырларга, дөрес итеп сулыш алырга өйрәтү. Сүзләрен ачык, аңлаешлы итеп әйтеп җырларга өйрәтү. | “Кыш”, Ф. Җәләлетдинова муз.; “Яңа ел”, Р. Ахиярова муз.; “Чыршы – чыршыкай”, Л. Хисмәтуллина муз.; “Ёлка – ёлочка”, Т. Попатенко муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Бирелгән текстка көйләр чыгару сәләтен үстерү. | “Елның дүрт фасылы”, Г. Тукай сүз. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре.* | Уен күнегүләрендә музыканың характерын чагылдырып, җиңелчә йөгерергә, ритмлы итеп сикерергә өйрәтү. | “Марш”, Р. Фәизова муз.; “Весёлые мячики”, М. Сатуллина муз. |
| | *б)Сәхнәләштерелгән этюдлар.* | Музыка характерына туры китереп, мөстәкыйль рәвештә авыр итеп атларга, дәртле итеп барабанчы хәрәкәтен ясарга өйрәтү. | “Аю”, Р. Еникеев муз.; “Барабанщик”, М. Красев муз. |
| | *в) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Түгәрәктә берәрләп һәм парлап йөрергә, әйләнергә өйрәтү. Төп хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү. Характерлы биюләрне музыканың характерына туры китереп, күренешләрне, образларны сәнгатьле итеп күрсәтә белергә өйрәтү. | “Чыршы янында”, И. Шәмсетдинов муз.; “Чыршы”, Л. Хисмәтуллина муз.; “Һай, Кыш бабай”, И. Шәмсетдинов муз.; “Кар бөртекләре биюе”, “Аю балалары биюе”, Р. Гыйләҗева муз.; “Петрушкалар бие”, Л. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Хисмәтуллина муз.; “Танец зайчат”, И. Штраус муз. (“Полька”). |
| | *г) Музыкаль һәм җырлы уеннар.* | Уен күнегүләрен сәнгатьле итеп күрсәтә, сәхнәләштерә белү сәләтен үстерү. Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп иҗат итәргә өйрәтү. | “ Кем беренче?”, т.х.к., Р. Сабитов эшк. “Кырдан килә Кыш бабай”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Җырның сүзләренә туры китереп, бию хәрәкәтләрен күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | “Курчак”, т.х.к., А. Монасыйпов эшк. |
| | *е) Балалар музыка уен коралларында уйнау.* | Балаларны бубенда ритмлы итеп уйнарга өйрәтү. | “Кура җиләк”, Л. Шиһабетдинова муз. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Ритмны тою сәләтен камилләштерү. | “Ритмические полоски”. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Татар халык җырларына уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. Күңелле бәйрәмнән балаларда шатлык хисләре уяту. | Татар халык җырлары. Халык авыз иҗаты. “Яңа ел”. Бәйрәм. |

| **Гыйнвар. Тема:“Кыш”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **2. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Балаларның музыка өлкәсендә белемнәрен үстерүгә булышлык итү. Музыканың эчтәлеген аңларга, тасвирлау чараларын ишетә белергә өйрәтү. | “Сәгать”, Ф. Әхмәтов муз.; “Бабай”, Җ. Фәйзи муз.; “Вальс – шутка”, Д. Шостакович муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Музыкада аваз югарылыгын ишетү сәләтен үстерү. | “Тавык һәм чебиләр”. |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Көйне дөрес итеп көйләргә, сәнгатьле итеп җырларга өйрәтү. | “Физзарядка”, Ф. Җәләлетдинова муз. |
| | *б) Җырлар.* | Җырларны сәнгатьле итеп җырларга, дөрес итеп сулыш алырга өйрәтү. Сүзләрен ачык, аңлаешлы итеп әйтеп җырларга өйрәтү. Бердәм башлап, бердәм тәмамларга өйрәтү. | “Кыш бабай”, Ф. Әбүбәкеров муз.; “Песи баласы”, Л. Хәйретдинова муз.; “Улыбка”, В. Шаинский муз. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *в)Җыр иҗаты.* | Бирелгән текстка көйләр чыгару сәләтен үстерү. | “Сыерчык”, Ф. Җәләлетдинова эшк. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Уен күнегүләрендә музыканың характерын чагылдырып, җиңелчә йөгерергә, түгәрәктән төрле якка таралышып, яңадан түгәрәккә тезелә белергә, ритмлы итеп сикерергә өйрәтү. | “Әйлән – бәйлән”, т.х.к.; “Татар полькасы”, А. Батыршин муз.; “В садике”, А. Майкапар муз. |
| | *б)Сәхнәләштерелгән этюдлар.* | Музыка характерына туры китереп, мөстәкыйль рәвештә җиңел хәрәкәтләр ясарга өйрәтү. | “Кем саный?”, Р. Ахиярова муз. |
| | *в) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Түгәрәктә берәрләп һәм парлап йөрергә, әйләнергә өйрәтү. Төп хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү. Характерлы биюләрне музыканың характерына туры китереп, сәнгатьле итеп хәрәкәтләнергә өйрәтү. | “Күңелле биибез”, баш.х.к., А. Кобагошев эшк.; “Кәрия – Зәкәрия”, т.х.ж., Р. Еникеева эшк. “Мәрҗән бөртекләре биюе”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *г) Музыкаль һәм җырлы уеннар.* | Уен күнегүләрен сәнгатьле итеп күрсәтә, сәхнәләштерә белү сәләтен үстерү. Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп иҗат итәргә өйрәтү. | “Куяннар һәм аю”, Ф. Шәймәрданова муз.; “Яулык биреш”, т.х.уены, В. Вәлиева эшк.; “Оркестр”, т.х.к., Г. Гыйләҗетдинова эшк. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Җырның сүзләренә туры китереп, бию хәрәкәтләрен күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | “Безнең чебиләр”, Г. Беляева муз. |
| | *е) Балалар музыка уен коралларында уйнау.* | Балаларны маракасларда ритмлы итеп уйнарга өйрәтү. | “Санамыш”. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Ритмны тою сәләтен камилләштерү. | “Тылсымлы маракаслар”. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Әкиятләргә кызыксыну тәрбияләү. Күңелле бәйрәмнән балаларда шатлык хисләре уяту, активлыкларын үстерү. | “Ике ялкау”. Сәхнәләштерелгән чара. (т.х.ә.) “Кыш”. Әдәби музыкаль кичә. |

| Февраль. Тема:“Ватанны саклаучылар көне” | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социал- | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **3. Музыка тыңлау.** *а) Музыка* | Балаларның музыка өлкәсендә белемнәрен үстерүгә булышлык итү, фикерләрен баету. Музыканың эчтәлеген аңларга, тасвирлау | “Авыру куян”, Р. Ахиярова муз.; “Куян биюе”, Р. Еникеев муз.; “Смелый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *әсәрен кабул итү.* | чараларын ишетә белергә өйрәтү. Контраст характердагы музыканы тыңлаганда, аңа карата эмоциональ җавап хисләре тәрбияләү. | наездник", "Всадник", Р. Шуман муз.; " |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Ритмны тою сәләтен үстерү. | "Зур һәм кечкенә аю". |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Көйне дөрес итеп көйләргә, сәнгатьле итеп көчәнмичә җырларга өйрәтү. | "Саескан", Г. Гыйләҗетдинова муз. |
| | *б) Җырлар.* | Җырларны сәнгатьле, моңлы итеп җырларга, дөрес итеп сулыш алырга өйрәтү. Сүзләрен ачык, аңлаешлы итеп әйтеп, бер темпта җырларга өйрәтү. | "Әниләр өчен бию", Ф. Шәймәрданова муз.; "Әбием – дәү әнием", Р. Гыйләҗетдинова муз.; "Про папу", И. Рыбкина муз.; "Мы запели песенку", Р. Рустамов муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Бирелгән текстка көйләр чыгару сәләтен үстерү. | "Дусларым", Ф. Җәләлетдинова муз. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Уен күнегүләрендә музыканың характерын чагылдырып, җиңелчә тасмалар тотып хәрәкәт итәргә, ритмлы итеп тыпырдап йөрергә өйрәтү. | "Йомшак куллар", Р. Гыйләҗева муз.; ""Сапожки скачут по дорожке", А. Филиппенко муз. |
| | *б)Сәхнәләштерелгән этюдлар.* | Музыка характерына туры китереп, ике өлештән торган музыканы истә тотып, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләрне үзгәртергә өйрәтү. | "Тигез юл буйлап", (т.х.к.), З. Ибраһимова эшк.; "Всадники", В. Витлин муз. |
| | *в) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Түгәрәктә предметлар белән берәрләп һәм парлап йөрергә, әйләнергә өйрәтү. Төп хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү.<br>Характерлы биюләрне музыканың характерына туры китереп, күренешләрне, образларны сәнгатьле итеп күрсәтә белергә өйрәтү. | "Яулыклар тотып бию", Л. Хисмәтуллина муз.; "Туган көн", М. Бикбова муз.; "Парный танец", Е. Тиличеева муз.; "Әни куян һәм куяннар", Р. Гыйләҗева муз. |
| | *г) Музыкаль һәм җырлы уеннар.* | Уен күнегүләрен сәнгатьле итеп күрсәтә, сәхнәләштерә белү сәләтен үстерү. Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп иҗат итәргә өйрәтү. | "Качыш", Р. Еникеев муз.; "Куяннар һәм бүре", М. Әндәрҗанова муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | "Ат", Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *е) Балалар музыка уен коралларында уйнау.* | Балаларны бубенда ритмлы итеп уйнарга өйрәтү. | "Кар малае", Г. Зәйнашева муз. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Ритмны тою сәләтен камилләштерү. | “Звонкие ладошки”. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Татар халык иҗатына, туган илгә мәхәббәт тәрбияләү.Күңелле бәйрәмнән балаларда шатлык хисләре уяту. | Татар халык уеннары.<br>Тематик кичә.<br>“Әти кебек булырмын”. Бәйрәм. |

| **Март. Тема:“ Халыкларның гореф гадәтләре, милли йолалары”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **1. Музыка тыңлау.**<br>*а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Балаларның музыка өлкәсендә белемнәрен үстерүгә булышлык итү, фикерләрен баету. Музыканың эчтәлеген аңларга, тасвирлау чараларын ишетә белергә өйрәтү. Җырларны кереш өлешеннән танып белергә өйрәтү. | “Әни кирәк”, М. Шәмсетдинова муз.; “Яз килгән”, Л. Б. – Болгари муз.; “Ласковая просьба”, Г. Свиридов муз.; “Мамины ласки”, А. Гречанинов муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Тембрны аера белү һәм динамик төсмерләрне ишетү сәләтен үстерү. | “Атта”, Ф. Әхмәтов муз., (p – f), (f – p). |
| | **2. Җырлау.**<br>*а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Күнегүне бер аваз югарылыгында көйләргә өйрәтү. | “Әтәч”, Дәрдмәнд сүз. |
| | *б) Җырлар.* | Җырларны сәнгатьле, моңлы итеп җырларга, музыкаль фразалар арасында дөрес итеп тын алырга өйрәтү. Сүзләрен ачык, аңлаешлы итеп әйтеп, бер темпта җырларга өйрәтү. | “Яз килә”, Ф. Шәймәрданова муз.; “Сыерчык”, И. Шәмсетдинов муз.; “Воробей”, В. Герчик муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Бирелгән текстка көйләр чыгару сәләтен формалаштыру. | “Карга”, Ф. Җәләлетдинова эшк. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.**<br>*а) Уен күнегүләре* | Уен күнегүләрендә музыканың характерын чагылдырып, җиңелчә тасмалар тотып хәрәкәт итәргә, ритмлы итеп тыпырдап йөрергә өйрәтү. | “Марш”, М. Салихов муз.; “Полька”, И. Якупов муз.; “Ат”, Ф. Шәймәрданова муз.; “Маленький танец”, Н. Александрова муз. |
| | *б)Сәхнәләштерелгән этюдлар.* | Музыка характерына туры китереп, ике өлештән торган музыканы истә тотып, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләрне үзгәртергә өйрәтү. | “Шаян мәче”, Ә. Шәрәфиев муз.; “Наседка и цыплята”, Т. Ломова муз. |
| | *в) Түгәрәк уеннары һәм* | Түгәрәктә предметлар белән берәрләп һәм парлап йөрергә, әйләнергә өйрәтү. Төп | “Күңелле бию”, Ф. Фәизова муз.; “Ак калач”, Р. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *биюләр.* | хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү. Характерлы биюләрне музыканың характерына туры китереп, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләрне үзгәртергә өйрәтү. | Еникеева муз.; “Чәчәкләр биюе”, Л. Хисмәтуллина муз |
| | *г) Музыкаль һәм җырлы уеннар.* | Уен күнегүләрен сәнгатьле итеп күрсәтә, сәхнәләштерә белү сәләтен үстерү. Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп иҗат итәргә өйрәтү. | “Тычканнар”, Р. Зарипова муз.; “Узнай по голосу”, Е. Тиличеева муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | “Чыпчыклар”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *е) Балалар музыка уен коралларында уйнау.* | Балаларны шылтыравыкларда ритмлы итеп уйнарга өйрәтү. | “Әпипә”.т.х.к., Ф. Җәләлетдинова эшк. |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Яраткан җырларына оркестровка өчен мөстәкыйль рәвештә музыка уен кораллары сайларга өйрәтү. | Белгән җырлар. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Балаларның әкиятләр турында белемнәрен ныгыту. Әниләргә, әбиләргә, тәрбиячеләргә мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү. Күңелле бәйрәмнән балаларда шатлык хисләре уяту. | “Торна белән төлке”. Курчак театры. “Әниләр бәйрәме”. Бәйрәм. |

| **Апрель. Тема:“Яз”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **2. Музыка тыңлау.** *а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Балаларда музыканы ярату хисләре, аны тыңлау теләге тәрбияләүне дәвам итү. Музыканың эчтәлеген аңларга, тасвирлау чараларын ишетә белергә өйрәтү. Музыка уен коралларының тавышларын ишетеп аера белергә өйрәтү. | “Туган тел”, т.х.к., Г. Тукай сүз.; “Күбәләк”, “Колын”, (Балаларга фортепиано өчен әсәрләр), Р. Ахиярова муз.; “Клоуны”, Д. Кабалевский муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Жанрны аера белергә өйрәтү, музыкаль хәтерләрен үстерү. | “Музыкаль кибет”. |
| | **2. Җырлау.** *а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Көйне дөрес итеп көйләргә, сәнгатьле итеп көчәнмичә җырларга өйрәтү. | “Бишек җыры”, т.х.к., Р. Миңнуллин сүз. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *б) Җырлар.* | Җырларны сәнгатьле, моңлы итеп җырларга, музыкаль фразалар арасында дөрес итеп тын алырга өйрәтү. Сүзләрен ачык, аңлаешлы итеп әйтеп, бер темпта җырларга өйрәтү. | “Яңгыр”, М. Бикбова муз.; “Бу – мин”, Л. Таһирова муз.; “Дождик”, р.х.җ., Ю. Слонов эшк. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Бирелгән текстка көйләр чыгару сәләтен үстерү. | “Санамыш”, Ф. Җәләлетдинова эшк. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.** *а) Уен күнегүләре* | Уен күнегүләрендә музыканың характерын чагылдырып, җиңелчә хәрәкәт итәргә, ритмлы итеп тыпырдап йөрергә, сикерешле адымнар ясарга өйрәтү. | “Түгәрәктә бию”, т.х.к., “Тыпыр – тыпыр”.; “Полька М. Глинка муз. |
| | *б)Сәхнәләште релгән этюдлар.* | Музыканың башын һәм ахырын билгеләп, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итәргә өйрәтү. | “Атлар”, баш.х.к., Р.Сәлмәнов эшк. |
| | *в) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Ике өлештән торган музыкага кушылып, хәрәкәтләрне мөстәкыйль рәвештә үзгәртергә өйрәтү. Төп хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү. Характерлы биюләрне музыканың характерына туры китереп, сәнгатьле итеп башкара белергә өйрәтү. | “Матур уен”, т.х.к., Р. Сабитов эшк.; “Бәбкәләр”, Ф. Шәймәрданова муз. |
| | *г) Музыкаль һәм җырлы уеннар.* | Уен күнегүләрен сәнгатьле итеп күрсәтә, сәхнәләштерә белү сәләтен үстерү. Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп иҗат итәргә өйрәтү. | “Сыерчык оялары”, (“Полька”), Р. Сабитов муз.; “Автобуска утырдык”, Л. Хисмәтуллина муз. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | “Лошадка”, Н. Потоловский муз. |
| | *е) Балалар музыка уен коралларында уйнау.* | Балаларны маракасларда ритмлы итеп уйнарга өйрәтү. | “Тышта яз”,Л. Шиһабетдинова муз. |
| | **II.Мөстәкый ль сәнгать эшчәнлеге** | Яраткан җырларына оркестровка өчен мөстәкыйль рәвештә музыка уен кораллары сайларга өйрәтү. | Белгән җырлары. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү. Күңелле бәйрәмнән балаларда шатлык хисләре уяту. | “Карга боткасы”. Бәйрәм. |

| **Май. Тема:“Җәй”** | | | |
|---|---|---|---|
| | **Музыка эшчәнлегенең оештыру формасы** | **Тәрбия һәм белем бирү бурычлары** | **Музыкаль репертуар** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| “Физик үсеш”, “Социаль-коммуникатив үсеш”өлкәләре белән интегральләштерү. | **I.Музыка шөгыльләре:** | **Максат:** Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис – тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү. | |
| | **3. Музыка тыңлау.**<br>*а) Музыка әсәрен кабул итү.* | Балаларның музыка өлкәсендә белемнәрен үстерүгә булышлык итү, фикерләрен баету. Төрле жанрдагы музыкаль әсәрләрнең эчтәлеген аңларга, тасвирлау чараларын ишетә белергә өйрәтү. | “Марш”, Н. Җиһанов муз.; “Сандугач”, Ә. Шәрәфиев муз.; “Жаворонок”, М. Глинка муз. |
| | *б) Музыкаль – дидактик уеннар.* | Жанрны аера белү һәм музыкаль хәтерләрен үстерү. | “Рәсемне сайлап ал”. |
| | **2. Җырлау.**<br>*а) Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре.* | Көйне дөрес итеп көйләргә, сәнгатьле итеп көчәнмичә җырларга өйрәтү. | “Күлмәк”, Н. Бакиева муз. |
| | *б) Җырлар.* | Җырларны сәнгатьле, моңлы итеп җырларга, музыкаль фразалар арасында дөрес итеп тын алырга өйрәтү. Сүзләрен ачык, аңлаешлы итеп әйтеп, бер темпта җырларга өйрәтү. | “Колын бара каладан”, М. Шәмсетдинова муз.; “Кошечка”, В. Витлин муз. |
| | *в)Җыр иҗаты.* | Бирелгән текстка көйләр чыгару сәләтен үстерү. | “Тиен”, Ф. Җәләлетдинова эшк. |
| | **3. Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр.**<br>*а) Уен күнегүләре* | Уен күнегүләрендә музыканың характерын чагылдырып, җиңелчә хәрәкәт итәргә, ритмлы итеп тыпырдап йөрергә өйрәтү. | “Уфа – Чиләбе”, т.х.к., Л. Шиһабетдинова эшк.; “Төймә”, т.х.к., Ә. Фәттәх эшк. |
| | *б)Сәхнәләштерелгән этюдлар.* | Музыка характерына туры китереп, ике өлештән торган музыканы истә тотып, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләрне үзгәртергә өйрәтү. | “Умырзая”, т.х.к., Р. Еникеева эшк. |
| | *в) Түгәрәк уеннары һәм биюләр.* | Ике өлештән торган музыкага кушылып, хәрәкәтләрне мөстәкыйль рәвештә үзгәртергә өйрәтү. Түгәрәктә берәрләп һәм парлап йөрергә, әйләнергә өйрәтү. Төп хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү. | “Бергәләшеп биик”, Р. Гыйләҗева муз. |
| | *г) Музыкаль һәм җырлы уеннар.* | Уен күнегүләрен сәнгатьле итеп күрсәтә белергә, җиңелчә йөгерергә һәм уен коралына сугырга өйрәтү. Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп иҗат итәргә өйрәтү. | “Бәр, шөлдерле барабанга”, т.х.к., В. Вәлиева эшк. |
| | *д) Биюле уен иҗатын үстерү* | Җырның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләрне күңелле итеп башкарырга өйрәтү. | “Весёлые лягушата”, Ю. Литовко муз. |
| | *е) Балалар музыка уен* | Балаларны агач таякларда ритмлы итеп уйнарга өйрәтү. | “Тыпыр – тыпыр”, т.х.к., Ф. Җәләлетдинова эшк. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *коралларында уйнау.* | | |
| | **II.Мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге** | Яраткан җырларына оркестровка өчен мөстәкыйль рәвештә музыка уен кораллары сайларга өйрәтү. | Белгән җырлары. |
| | **III.Күңел ачу чаралары һәм бәйрәмнәр.** | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен киңәйтү. Күңелле милли бәйрәмнән балаларда шатлык хисләре уяту. | “Шәһәр урамында”. Курчак театры.<br>“Сабантуй”. Бәйрәм. |

**2.2. Комплексы - тематик план**

<u>Комплексы – тематик планлаштыру.</u>

| **Ай** | **Атна** | **Тема** | **Бурычлар** | **Үткәрелгән чаралар** |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь. | 1 | “Без балалар бакчасында” | 1)балаларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыруны дәвам итү, ягымлы сүз-ләр куллану хисабына сүзлекләрен актив-лаштыру;<br>2) балаларның кызыксынуын,игътибарын хәтерен үстерү;<br>3) балаларда дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. | “ Белем көне” бәйрә-ме үткәрү. Балалар бакчасы хезмәткәр-ләре һәм ата-аналар катнашында. |
| | 2 | “Безнең яраткан апабыз” | 1) тәрбияче ярдәмчесе һөнәре турында балаларның күзаллауларын формалашты-руны, таныш һөнәрләр атамасын ныгы-туны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, сүз байлыгын үстерү;<br>3) балаларда зурлар хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү. | Тәрбияче ярдәмчесе турында презентация карау. |
| Октябрь | 1 | “Басуга бару” | 1) балаларның транспорт (поезд) һәм аның төп билге-ләре (төс, материал) бе-лән таныштыруны дәвам итү, яшелчәләр (кишер, чөгендер) турындагы белемнәрне ныгыту;<br>2) яшелчәләрнең тышкы күренеше, тәме, формасы буенча (кишер, чөген-дер) аера белү осталыгын, игътиба-рын, кабул итү-ләрен, диалоглы сөйләмен, сенсор сәләт-ләрен үстерү, [у] авазын дөрес әйтүләре-нә ирешү;<br>3) балаларда табигатькә уңай караш тәр-бияләү. | “Көз”темасына ба-гышланган балалар иҗаты күргәзмәсе оештыру. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2 | “Куян кучтәнәчләре” | 1) балаларның көз, көзге уңыш турында-гы күзаллауларын киңәйтү, яшелчәләр (кыяр, суган, помидор) турындагы белем-нәрен ныгыту;<br>2) яшелчәләрне (кыяр, суган, помидор) тышкы күренеше буенча аера белү оста-лыгын, игътибарын, кабул итүләрен, диа-логлы сөйләмен, сенсор сәләтләрен үсте-рү;<br>3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. | “ Безнең бакчада нәрсәләр үсә?” хоро-водлы уен уйнау |
| | 3 | “Әти, әни һәм мин” | 1) балаларны көзнең характерлы бил-геләре белән таныштыруны дәвам итү, көзге яфраклар турындагы белемнәрне тирәнәйтү, күгәрченнең тышкы кыяфәтен, хәрәкәтләрен ныгыту, [ш], [г] авазлар әйтелешен активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү-ләрен, хәтерен, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) балаларда пөхтә эшләү теләге һәм кошлар турында кайгыртучанлык тәр-бияләү. | Тәрбиячеләр һәм ата-аналар катна-шында “ Сәламәт-лек көне” чарасын үткәрү. |
| | 4 | “Мин һәм кешеләр” | 1) балаларның гаиләләре турындагы күзаллауларын киңәйтү;.<br>2) балаларның фикерләвен, хәтерен, хәрәкәт активлыгын үстерү;<br>3) балаларда туганлык хисләре тәрбия-ләү. | Балалар иҗаты күргәзмәсе оештыру. |
| Ноябрь | 1 | “Мин үзем өчен иң кадерле кеше” | 1) балаларга кешенең үсеше турында күзаллаулар бирү, төрле яшьтәге һәм җенестәге кешеләрне аерырга өйрәтү, кешеләрнең бер – берсеннән аерылып торуын (яше, җенесе белән генә түгел, ә характер үзенчәлекләре, киеме, шөгыле белән дә аерылуын) аңлату;<br>2) сөйләмнәрен, логик фикерләүләрен үстерү;<br>3) әйләнә - тирәгә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү. | “ Кемнәр алар якын кешеләр?” те-масына шигырь ки-чәсе оештыру |
| | 2 | “Минем данлыклы шәһәрем” | 1) балаларны туган шәһәр белән таныш-тыруны дәвам итү, шәһәрнең тарихы, Татарстан Республикасы турында белем бирү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътиба-рын, диалоглы сөйләмен үстерү; | Тәрбиячеләр һәм физ.инструктор катнашында спорт бәйрәмен уздыру. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 3) балаларда туган шәһәр белән горур-лану хисләре, төзүче һөнәренә хөрмәт тәрбияләү. | |
| | 3 | “Минем Туган илем – Рәсәй” | 1) балаларда туган ил, аның тарихы, әләм флаг турында күзаллаулар формалашты-ру;<br>2) балаларның кабул итүләрен, сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтү осталыгын, игътибарын үстерү;<br>3) балаларда туган илгә мәхәббәт, төгәл-лек тәрбияләү. | Балаларның иҗат күргәзмәсен оешты-ру |
| | 4 | “Минем шәһәрем урамнары” | 1) балаларда туган шәһәрләре, аның тари-хы турында күзаллаулар формалашты-ру;<br>2) балаларның кабул итүләрен, сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтү осталыгын, игътибарын үстерү;<br>3) балаларда туган илгә мәхәббәт,төгәл-лек тәрбияләү. | Ата-аналар ярдә-мендә ясалган “Ми-нем шәһәрем”фото альбом күргәзмәсе оештыру . |
| | 5 | “Туган ягымның бай хазинәләре ” | 1)Нурлат-нефть чыганагы булуны аңлату.<br>2) Районыбыздагы музей турында мәгълүмат бирү,<br>3)туган ягыбызга карата кызыксынучанлык, хөрмәт тәрбияләү. | Рәсемнәр күргәзмәсе оештыру. |
| Декабрь | 1 | “Хуш килә-сең,карлы кыш!” | 1 балаларның кыш, белемнәрен тирәнәй-тү, сөйләмнең грамматик төзелешен ка-мил-ләштерү;<br>2) кабул итүне, игътибарны, сүзлекне, бәйләнешле сөйләмне үстерү;<br>3) биремнәрне үтәүгә кызыксыну тәрбия-ләү. | “Кышкы уеннар” бәйрәме уздыру. |
| | 2 | “Киемнең үткәне һәм бүгенгесе” | 1) балаларны киемнең билгеләнеше һәм функцияләре белән таныштыру, кием материалы һәм аны куллану ысулы ара-сындагы бәйләнешне урнаштырырга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, диа-логлы сөйләмен, кызыксынуын, иҗади сәләтләрен үстерү;<br>3) балаларда зәвык тәрбияләү. | Ата-аналар ярдәмен-дә өстәл өсте уенна-ры әзерләү. |
| | 3 | “Яңа ел уенчыклары” | 1) балаларны Яңа ел бәйрәмен каршы-ларга әзерләү, чыршы уенчыклары белән таныштыру, пыяладан ясалган уенчык-ларның, предметларның билгеләрен ачыклау (үтә күренмәле, төсле, шома, салкын, | Спорт уеннары бәйрәмен уздыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ватылучан);<br>2) балаларның сенсор сәләтләрен һәм<br>кызыксынуын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү. | |
| | 4 | “Яңа ел килә” | 1) балаларда Яңа ел бәйрәме турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү, сенсор билгеләре буенча бертөрле пред-метларны төркемгә берләштерү осталы-гын ныгыту;2) балаларның чыршы уен-чыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын билгеләү, диалоглы сөй-ләмен, сорауларга җөмлә белән җавап би-рү осталыгын, хисси тәҗрибәсен, кабул итүләрен үстерү;<br>3) балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре уяту | “ Яңа ел” бәйрәме уздыру. |
| Гыйнвар | 1 | “Кыш билгеләре” | 1) балаларның кыш турында белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның күрсәтмә образлы фикер-ләвен үстерү;<br>3) туган табигатькә мәхәббәт һәм эстетик хисләр тәрбияләү. | “ Кыш” бәйрәмен уздыру.Балалар иҗа-ты күргәзмәсе |
| | 2 | “Кар бабай” | 1). балаларның кышкы күренешләр ту-рындагы күзаллауларын киңәйтү, гео-метрик фигураларның – түгәрәкнең, өч-почмакның атамасын ныгыту, деталь-ләрне зурлыгы буенча чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2). балаларның кабул итүләрен, игътиба-рын, фикерләвен үстерү;<br>3). балаларда уңай эмоциональ халәт бул-дыру, эстетик хисләр тәрбияләү. | Балалар иҗаты күргәзмәсе оештыру. |
| | 3 | “Җәнлекләрнең кышка тормышы” | 1) балаларны җәнлекләрнең кышкы таби-гатьтә яшәү рәвеше белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның грамматик яктан дөрес сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда тере табигатькә карата кы-зыксыну тәрбияләү. | Дидактик уеннар әзерләү. Ата-аналар ярдәмендә |
| | 4 | “Җәнлекләр кышкы урманда” | 1) балаларның кыргый хайваннар турын-да күзаллауларын формалаштыру; таби-гатьтәге сезонлы үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) бәйләнешле сөйләм үстерү, | Рәсем күргәзмәсе оештыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>3) хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү. | |
| Февраль | 1 | “Бакчабызның балта остасы” | 1) балаларны олылар хезмәте белән та-ныштыруны дәвам итү (балта остасы хез-мәте), хезмәт кораллары турындагы бе-лемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү, хезмәт коралларын классификацияләү осталыгын, игътиба-рын, олылар хезмәтенә карата кызыксы-нуын үстерү;<br>3) өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. | Сәламәтлек көне оештыру |
| | 2 | “Безнең армия” | 1) балаларда илне саклаучы сугышчылар турында күзаллау формалаштыру, “Ватанны саклаучылар” төшенчәсен ачыклау. Кайбер хәрби һөнәрләр (диңгезчеләр, танкистлар, очучылар, чик сакчысы) белән таныштыру;<br>2) балаларның сорауларга тулы фра-залар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, кызыксынуын үстерү;<br>3) хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, пат-риотлык хисләр тәрбияләү. | Ватанны саклаучы-лар көненә багыш-ланган бәйрәм узды-ру |
| | 3 | “Без – солдат-лар!” | 1) балаларны Ватанны саклаучы-лар көне белән таныштыру, оч-кычның (самолет), вертолетның өлешләрен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмә-ләре формалаштыруны дәвам итү, солдат, очучы, диң-гезче, очкыч, вертолет, кораб сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, кызыксынуын үстерү;<br>3) балаларда очучы, диңгезче, хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, патриотик хисләр, малайларда көчле, кыю булу теләге тәрбия-ләү. | Балалар иҗат күр-гәзмәсен оештыру |
| Март | 1 | “Әнием турында сөйлим” | 1) бәйрәмнәр белән таныштыруны дәвам итү; әниләр турында тасвирлама төзү ос-талыгын формалаштыру;<br>2) кабул итүне, хәтерне, игътибарны, сүз-лекне үстерү, сәнгатьлек чараларын кул-ланууда | Ата-аналар катна-шында “8 нче Март” бәйрәмен уздыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | күнектерү;<br>3) әниләргә хөрмәт тәрбияләү. | |
| | 2 | “Музыка җитәкчесендә кунакта” | 1) балаларның әниләр бәйрәме, әниләре турындагы белемнәрен киңәйтү, музыка җитәкчесенең бербөтен образын тудыру; музыка коралларының төп билгеләрен ачыклау;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, диалоглы сөйләм формасын, шигырьләрне сәнгатьле сөйләү ос-талыгын үстерү;<br>3) балаларда әниләргә, музыка җитәкче-енә карата ихтирам, хөрмәт тәрбияләү. | Балаларның рәсем күргәзмәсен оештыру |
| | 3 | “Савыт-саба” | 1) татар авылы көнкүреше белән таныш-тыру; хәзерге һәм элекке заманда кулла-нылган савыт-саба турындагы белемнәр-не ныгыту;<br>2) кабул итүләрен, фикерләүләрен, хәтер-ләрен сүзлек байлыгын үстерү, сөйләм-нең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>3) татар халкының көнкүреш предметла-рына кызыксыну тәрбияләү. | Ата-аналар ярдәмен-дә дидактик уен ясау |
| | 4 | “Кием – салым” | 1.) татар халкының көнкүреше белән та-ныштыру; хәзерге һәм элекке заманда киелгән киемнәре турында турындагы белемнәрне ныгыту;<br>2) кабул итүләрен, фикерләүләрен, хә-терләрен сүзлек байлыгын үстерү, сөй-ләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;3) татар халкының көнкүреш пред-метларына,кием - салымына кызык-сыну тәрбияләү. | Балалар иҗаты күргәзмәсе оештыру |
| Апрель | 1 | “Кар бабай язны эзли” | 1) балаларның ел фасыллары, кыш, яз билгеләре турындагы белемнәрен ныгы-ту, табигать күренешләре һәм алар ара-сындагы бәйләнеш турындагы күзаллау-ларын формалаштыру, кояш, кошлар, умырзая чәчәге, җир казый, орлык чәчә кебек сүзләр һәм сүзтезмәләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, кы-зыксынуын, фикерләвен, хәрәкәт актив-лыгын үстерү;<br>3) балаларда табигатькә карата | “ Нәүрүз”бәйрәмен үткәрү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. | |
| | 2 | “Яз бүләкләре” | 1) балаларның яз, аның билгеләре турындагы белемнәрен, бер, күп төшенчәсен куллану-ларын ныгыту, бишкә кадәр са-нарга өйрәтү, киң, тар, яңгыра-вык, күңелле, тыныч тавыш, кычкырып сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру, табигать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнешләрне аңлатуны һәм яз көне башкары-ла торган эш турындагы күзал-лауларын формалаштыруны дәвам итү, куркынычсызлык кагыйдәләре турындагы белем-нәрен киңәйтү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен,фикерләвен, ишетү сәләтен, кабул итүләрен үстерү;<br>3) балаларда табигатькә карата сакчыл караш, кайгыртучалык, үзара дуслык хисләре тәрбияләү. | Рәсемнәр күргәзмәсен оештыру |
| | 3 | “Космонавтлар көне” | 1) балаларның космонавтлар турында белемнәрен арттыру, космонавтлар б\н таныштыру;<br>2) ) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, , кабул итүләрен үстерү;<br>3) балаларда космоска карата кызыксы-нучанлыкларын,үзара дуслык хисләре тәрбияләү. | Балалар иҗаты күргәзмәсе оештыру |
| | 4 | Яз килә, яз! | 1) балаларның яз, аның айлары, билгеләре турындагы белемнә-рен ныгыту, эшчәнлектә кул-ланган сүзләр хисабына сүз-лекләрен активлаштыру, таби-гать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнеш турын-дагы күзаллауларын формалаш-тыруны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, кызыксынуын, фикер-ләвен, хәрәкәтен, кабул итү-ләрен үстерү;<br>3) балаларда табигатькә карата сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. | Урамда язгы уеннар бәйгесе оештыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 4 | “Без әкият яратабыз” | Балаларны әкиятләрне сәхнәләштерергә өйрәтү. Театр төрләре белән таныштыру. Өйрәнгән әкиятләре турында күзаллау формалаштыру. Халык әкиятләре белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының исемнәрен ныгыту. Халык аваз иҗатына карата кызыксыну уяту, хөрмәтлелек тәрбияләү | “ Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерү. |
